## Илһам Вәлиев: «Чын җырчылар хәзер модада түгел»

«Хәзер сәхнәгә табын җырчылары, тамадалар менде шул. Табын арты форматы булса, керемлерәктер эстрада. Чын җырчылар хәзер модада түгел. Бу – заман шаукымы, бәлки ул үтеп тә китәр. Тик бер әйбер – аларның үзебезнең туган телдә җырлаулары гына шатландыра».

12 БИТ

## Сабан туен үткәрмичә ярамый

Июль – Сабан туйлары ае. Авылларда шау-гөр килеп бәйрәмгә әзерләнәләр. Бизәлгән атлар, гармун тавышы, чигүле сөлгеләр, җыр-бию, уен-көлке... Электән килгән гореф-гадәт – Сабан туе алдыннан бирнә җыялар. Сөрән сугу, сөлге җыю, бирнә әзерләү, әрәпә – төрле якларда төрлечә аталса да, асылы бер.

4 БИТ


1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

# Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 29.06.2017 | № 69 (5831) www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ


# УРМАННАРГА КЕРСӘҢ, СЫЗГЫРЫП КЕР

**Бу юлы авылга кайтканда, урман кырыйларында туктаган машиналарга күз төште. Былтыр каен җиләге 13 июньдә үк өлгергән булса, быел әле ул шау чәчәктә. Июнь азагында урманда тагын нәрсә эшләп була икән дисәм, гөмбә җыя икән халык. Каен гөмбәсе бик күп, ди. Кайберәүләр мунча себеркесе әзерли башлаганнар. Урманның байлыгы җитәрлек җитәрлеккә, тик талпаннар, еланнар күп дип зарланучылар да бар.**

5 БИТ

kp.ru

АЛАР МӘҢГЕЛЕККӘ ДИҢГЕЗ БУЕНА КИТТЕ

10 БИТ

«АЛТЫН ЯКИ КӨМЕШ САВЫТ-САБА КУЛЛАНУ ХӘРАМ»

13 БИТ

## РЕСПУБЛИКАДА

**ЧАЛЛЫ**

Шәһәр тарихы һәм туган якны өйрәнү музеенда самавырлар күргәзмәсе ачылган. Биредә төрле чорда, төрле төбәктә, чит илләрдә дә эшләнгән 100гә якын самавырны күрергә мөмкин. Араларында патша заманында ясалганнары да бар икән.

**ӘЛМӘТ**

28 яшьлек Радель Бакиров велосипед белән Кырымга юл тоткан. 23 көн эчендә ул 2350 чакрым юл үтәргә исәпли. Кырымда шифаханәдә дә ял итәргә уйлый. Велосәяхәтен социаль челтәрдә яктыртып барачак.

**КАЙБЫЧ**

Сугым пунктлары – район өчен мөһим объектларның берсе. Мәлки авылында Азат Шәйдуллин ветеринария таләпләренә туры китереп эшләнгән мал чалу цехын төзеткән. Цехта бер сменага 10-15 баш мөгезле эре терлек чалып эшкәртергә мөмкин. Итне вакытлыча саклау өчен 10 тонна сыйдырышлы суыткыч та бар.

**ЧИРМЕШӘН**

Әмир авылында яшәүче Бадаевлар биш баш сыер асрый. Хәзер аларның малларын «электр көтүче» көтә. Пай җирләренең бер өлешен – бер гектарга якын мәйданны алар «электр көтүче» өчен әйләндереп алганнар. Моны сыерларны саклау өчен бик кулай җиһаз дип саныйлар.

**ЯШЕЛ ҮЗӘН**

Норлат авылында баскетбол һәм волейбол уйнарга бөтен мөмкинлекләре булган спорт мәйданчыгы ачылган. Норлатлылар өчен бу – көтеп алынган бүләк. Авылда спортка тартылучы яшьләр арта бара, Идел аръягы авыллары арасында Норлат кызлары командасы волейбол ярышында иң көчлеләре икән. Спорт мәйданчыгын булдыру 2 миллион сумга төшкән.

**Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды**

# Уку йортларында «урак өсте»: бюджет урыннары кимегән, бәяләр арткан

**Узган атнада югары уку йортларында абитуриентларның документларын кабул итә башладылар. Быел Татарстанда барлыгы 14,5 мең укучы мәктәпне тәмамлады. Министрлар Кабинетында узган брифингта быелгы кабул итү кампаниясенең яңалыклары турында сөйләштеләр.**

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Республиканың югары уку йортларында 15806 бюджет урыны каралган. «Бу, узган ел белән чагыштырганда, 1,5 процентка кимрәк», – ди Татарстан мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов. Быел белгечлек юнәлешенә – 1247, магистратурага – 5252 , бакалавриатка 9307 кеше кабул итәчәкләр. «Мәгълүмат технологияләре», «химия», «электроника, радиоэлектроника һәм системалар», «физик тәрбия һәм спорт» кебек юнәлешләргә урыннар артса, гуманитария өлкәсендә, киресенчә, «тел һәм әдәбият», «сервис һәм туризм», «архитектура», «икътисад һәм идарә», «юриспруденция» белгечлегенә урыннар киметелгән.

Төп яңалыкларның берсе – быел Казан федераль университетында түләүле бүлектә белем алучылар өчен бәяләр арткан. Университетның беренче проректоры Рияз Минзарипов әйтүенчә, университеттан белгеч булып чыгу өчен, студентларга елына кимендә 102 мең сум түләргә кирәк булачак. Сүз уңаеннан, былтыр бу сумма елына 64 мең сум гына булган. Хәзерге вакытта КФУга инде 2 меңнән артык гариза кабул ителгән. Мәктәпләрдә аттестатлар әле узган атнада гына тапшырыла башлады. Документ бирүчеләр киләсе көннәрдә тагын да артыр, мөгаен. Гадәттәгечә, рейтинг буенча иң кыйммәтле белгечлек — теш табибы. КФУда инглизчә белем бирә торган стоматология бүлегендә уку елына 450 мең сумга төшә.

Икенче яңалык – Казан илкүләм тикшеренү технологияләр университетында (КХТИ) яңа ректор – Сергей Юшко. Быел анда читтән торып уку бүлегендә магистратурага 21 бюджет урыны бүлеп бирелгән.

Казан Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясендә 600 бюджет урыны исәпләнә. Ректор Йосыф Якубов әйтүенчә, биредә уку зур тырышлык сорый. «Студентның спорт өлкәсендәге казанышларына гына карамыйбыз, яхшы укыганга игътибар бирәбез», – ди ул.

Казан дәүләт төзелеш-архитектура академиясендә татарча уку мөмкинлеге дә бар.

Быелдан физик мөмкинлекләре чикләнгән абитуриентлар өчен укырга керү таләпләре гадиләштерелгән. Хәзер алар, уку йортының кабул итү комиссиясенә медицина социаль-экспертиза нәтиҗәсе урынына, инвалидлык турында белешмә генә тапшыра ала.

***Республикада 24 югары уку йорты һәм 20 филиал исәпләнә. Шуларның 30га якыны – дәүләтнеке. Югары уку йортларында документлар кабул итү 20 июньнән 26 июльгә кадәр дәвам итәчәк. Укырга кергәннәрнең тулы исемлеге 8 августта билгеле булачак. Һәр абитуриент берьюлы биш уку йортына өч юнәлеш буенча документ тапшыра ала.***

Тагын бер хәбәр – Россиянең Илкүләм гвардия хәрбиләре һәм аларның балалары югары уку йортына ташлама белән кабул ителүчеләр исемлегенә кертелгән. Ә менә Кырымнан килгән студентларга ташламалар бетерелгән. Алар, башкалар кебек үк, БДИ нәтиҗәләре буенча кабул ителәчәк.

## Шәһәр кәефе

**РАШАТ НАДЫРШИН,**
машина йөртүче:

– Казанда үзәктән читтәге торак комплексларда да берничә катлы автопаркинглар күпләп төзелсен иде. Ишегаллары машиналар белән тулды. Паркингларга бәя арзан булса, кешеләр аңа машиналарын һичшиксез куячак. Искра һәм Дементьев урамнарында юл-транспорт чишелешләрен күрергә хыялланам. Анда бөкеләр еш була. Урманнар куенындагы туган авылым Күкигә кайту – җанга шифа. Туган як матурлыгы чит ил күренешләреннән мең өстен.

**АЛСУ МУСАБИРОВА,**
рәссам:

– Казанда Фешин исемендәге сәнгать көллиятен һәм Мәскәүдә Суриков исемендәге сәнгать институтын тәмамладым. Күңнән бизәкләр ясарга яратам. Татар кешеләре милли киемнәребезне киеп йөрсеннәр иде. Шулкадәр матур бит милли киемдәге кеше. Парижда үткәрелгән Сабан туенда катнаштык. Французлар татар киемнәре, сувенирлар белән кызыксынды. Европаның башка илләреннән килгән татарлар түбәтәйләр, калфаклар сатып алды.

**МИЛӘҮШӘ ГАЛИУЛЛИНА,**
әдәби хезмәткәр:

– Казанның Европа дәрәҗәсенә күтәрелгәнлегенә сөенәбез сөенүен, ләкин мине шәһәребезнең милли төсмере югала баруы борчый. Йортлар һәм биналар татарның милли бизәкләрен кулланып төзелсен иде. Бөтенесе дә алай була алмый, әлбәттә, күпмеседер. Кафеларда төрек, үзбәк көйләре яңгырап тора, яңгырасын, тик татар җыр-көйләрен дә ишетик. Европа илләре туристларына мондагы «Европа» кирәк түгел, аларны милли яшәеш, үзенчәлек кызыксындыра.

**ЛИЛИЯ МИҢНЕХАНОВА,**
тележурналист:

– Түбән Камадан мин, Казанда яши башлаганыма – җиде ел. Конфедерацияләр Кубогының Казандагы матчларын яктыртуда катнашабыз. Чит ил спортчыларының, туристларның Казанга сокланып әйткән сүзләре горурлану тудыра. Казанда башка вакытларда халык өчен Сабантуй шикелле массакүләм мәдәни-спорт чаралары оештырылсын иде, ләкин ул бушлай булсын. Сингапурны мактыйлар, бер барып күрергә уйлыйм. Нәрсәләр бар икән анда?

**РАМИЛ ГАЛИ,**
фотограф:

– Нәсел тамырыбыз Казаннан, әмма мин Сочида туганмын. Анда 18 яшькә кадәр яшәдем, ә армиядән соңгы тормышым Казан белән бәйле. Хезмәт дәверендә Татарстанның бөтен районнарын йөреп чыктым, зур фотоархив тупладым. Татарстаным турында фотоальбом чыгарасым килә. Казанда «Фотомузей» оештырылсын иде. Электрон архив ул ышанычлы түгел. Шушы музейга мин дә, башкалар да фоторәсемнәрне китерер иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

# Вертолет сыйныфы укучылары аттестатны заводта алды

Мәктәпләрдә чыгарылыш кичәләре гөрли. Ә менә Татарстандагы вертолет сыйныфын тәмамлаучыларның бәйрәмнәре аеруча үзенчәлекле узды. Аттестатларын алар Казан вертолет заводы бинасында алдылар.

Заводта лаеклы ялга чыккан тәҗрибәле белгечләрне алмаштырырдай яшьләрнең җитмәвен сизеп, Казан вертолет заводы җитәкчесе Вадим Лигай «югары дәрәҗәле хезмәткәрләрне мәктәп бусагасыннан ук әзерләргә» кирәк дигән фикергә килә. Шул рәвешле, моннан сигез ел элек Казанның 8нче гимназиясендә беренче вертолет классы ачыла. Соңрак бу рәтләргә 54нче мәктәп тә кушыла. Быел бу ике вертолет классын 52 укучы тәмамлады.

Укучыларның йөзендә – дулкынлану катыш шатлык, моңсу елмаю, киләчәккә өмет, хыяллар.

– Булачак һөнәрем буенча укырга керү өчен, математика фәнен яхшы белергә кирәк. Шуңа да IX сыйныфтан соң вертолет сыйныфына күчтем. Уку җиңел булмады, төгәл фәннәргә зур игътибар бирелә иде, күп тырышырга туры килде. Вертолет классында малайлар күбрәк, бездә 25 укучының бары 8е генә кызлар иде, – ди 54нче мәктәпне тәмамлаучы Настя Аксенова.

8нче гимназия укучысы Булат Шамилов әтисе сайлаган юлны дәвам итәргә, инженер булырга хыяллана.

– Нәкъ менә вертолет классында физика, математиканы ныклап өйрәнгәнгә, Бердәм дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшыра алдым. Завод стеналарында узган чыгарылыш кичәсе безнең күңелләрдә озак сакланыр. Монда бик матур, чиста, кызык. Укыган чакта да биргә килгәнебез булды. Беренче тапкыр вертолетны күргәч, хәтта очучы буласым килгән иде, – ди Булат.

Яшьләргә завод җитәкчесе Вадим Лигай да хәер-фатихасын бирде.

– Сез бу тормышта үз урыныгызны табарсыз дип уйлыйм. Кулдан килгәннең барысын да эшләдек. Сезгә ныклы белем бирергә тырыштык. Хәзер күңелегезгә хуш килгән, ихтыяҗларыгызны канәгатьләндерерлек һөнәр сайлагыз, бәхетле булыгыз, – диде ул.

Чарада Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Илдар Мөхәммәтов та катнашты. «Кечкенәдән, киләчәктә төп транспорт чарасы очкычлар булыр, дип хыялландым. Кыскасы, киләчәк – сезнең кулда», – дип мөрәҗәгать итте ул чыгышында укучыларга.

Бәйрәм концерт программалары, чыгышлар белән үрелеп барды. Барлык укучыларга аттестат белән бергә ноутбуклар алырга сертификатлар да тапшырылды. Чара кысаларында Казан вертолет заводы белән Татарстандагы Талантлар университеты арасында уртак хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Әлеге университет дәүләт программасы кысаларында талантлы балалар һәм яшьләрне ачыклап, аларның сәләтләрен үстерү, бу потенциалны республика үсешенә җәлеп итү максаты белән оештырылган.

**Эльвира МОЗАФФАР.**

**Булат Зиннуров,**
Казан илкүләм тикшеренү технология университетының административ эшләр һәм филиаллар буенча проректоры:

*– Безнең уку йорты Казан вертолет заводы белән күптән хезмәттәшлек итә. Вертолет классын тәмамлаган укучыларның да күбесе безгә укырга килә. Уку йортында белем алу өчен барлык шартлар тудырылган. Студентларга Германиядә белемнәрен эстәү мөмкинлеге дә бар. Әле менә быел университет ишегалдына Ту-144 очкычын китереп куйдык. Киләчәктә монда интерактив авиация музее булачак дип ниятлибез. Кыскасы, уку йортыбыз тормыш өчен канатлар бирә.*

**Марина Пичугина,**
8нче гимназия директоры:

*– Бу чыгарылыш безнең өчен аеруча истәлекле. Быел гимназия статусында соңгы чыгарылышыбыз. 1 сентябрьдән без, тагын бер мәктәп белән кушылып, мәгариф үзәге дип атала башлаячакбыз. Безнең белән хезмәттәшлек иткән уку йорты галимнәренә зур рәхмәт.*

**Татьяна Алексеева,**
54нче мәктәп директоры:

*– Безнең өчен күп нәрсә беренче тапкыр: заводка килү, вертолет классының чыгарылышы. Иң мөһиме – соңгысы булмасын. Бүген укучылар үзләренең язмышларын хәл итә. Уңышлар телик аларга.*

## КҮРШЕЛӘРДӘ

Көн саен яуган яңгырлар аркасында, **Башкортстанның** 11 районында гадәттән тыш хәл игълан ителгән. Артык дым чәчелгән уңышка зыян китерә, ди Башкортстан Авыл хуҗалыгы министрлыгы. Кырлар су астында, хәтта бу күләвекләрдә кошлар йөзеп йөри икән. Бакчачылар да: «Яшелчәләр үсми, сарымсак, җиләк саргая, чери», – дип зарлана.

**Мари Элда,** экотуризмны үстерү максатында, җирле умартачылар җитештергән балны сатуга тәкъдим итәргә җыеналар. Моның өчен «Марий Отар» (Мари умарталыгы) брендны белән савытлар, каплар ясарга кирәклеге хакында да сөйләшкәннәр. Бу мәсьәләдә Мари Эл авыл хуҗалыгы министры республиканың умартачылар җәмгыяте вәкилләре белән очрашып фикер алышкан.

**Чувашстанда** соңгы биш ай эчендә туучылар саны 17,9 процентка кимегән, үлүчеләр саны арткан. Үлемгә китергән сәбәпләрнең күп очракта йөрәк-кан тамырлары, яман шеш авырулары һәм төрле тән җәрәхәтләре алу белән бәйле икән.

## ТОП – 3

**РЕСПУБЛИКА** клиник онкология диспансерында онкология буенча төгәл диагноз куярга мөмкинлек бирүче Россиядә бердәнбер МРТ 3 Тесла томографын тәкъдим иттеләр. Аның ярдәмендә аерым әгъзаны гына түгел, бөтен организмны тикшереп була. Томограф магнит кырына нигезләнеп эшли. Теләсә нинди металл предмет әлеге кырга эләккәч, тәэсир сизелә башлый. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та яңа томограф магнит кырының көчен учына 10 сум тимер акча салып сынап карады. Яңа җиһаз ярдәмендә диагностика сурәтләре югары сыйфатлы килеп чыга, тикшерену вакыты 30 минуттан 20 минутка кадәр кыскара.

**«АВТОВАЗ»**да автомобиль сатуда нык үсеш күзәтелә, дилерларга машина җитми, дип хәбәр итә» Российская газета». Аеруча седан Lada Vesta, универсал һәм фургон Largus, хетчбэк Xray модельләренә ихтыяҗ зур, ди. Аларны хәтта тиз генә сатып алып та булмый, салоннарга кайтарылуын ике атна тирәсе көтәргә туры килә. Сентябрьгә «АвтоВАЗ» аена 29 меңгә кадәр машина җитештерергә ниятли.

**МӘКТӘПЛӘРДӘ** яңа фән барлыкка килергә мөмкин – фамилистика. Татарстан Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева әйтүенчә, бу фән гаилә кыйммәтләрен өйрәнүгә багышланачак. Тулы, тату гаиләдә яшәргә кечкенәдән өйрәтергә кирәк, дип саный Президент ярдәмчесе. Баксаң, сораштырулардан күренгәнчә, укучылар үзләре мәктәпләрдә гаилә турында фән кертергә кирәк дип сораганнар.

*Казанга кабат әйләнеп кайту шундый күңелле! Җылы каршы алганыгыз, теләктәшлегегез өчен зур рәхмәт. Без моны беркайчан да онытмабыз!*

**Португалия җыелма командасының Конфедерацияләр Кубогының ярым финалы матчы алдыннан Твиттерда язган хәбәреннән.**

# Идел аша – паромда

**Казанда паромлы кичү эшли башлады. Ул Аракчинодан Югары Осланга 20 минут эчендә чыгарга мөмкинлек бирә.**

Баксаң, бу паром элек тә булган, әмма 1980 елдан бирле эшләмәгән. «Волгадорстрой» җаваплылыгы чикләнгән ширкәте паромлы кичүне яңартырга булган. Сүз уңаеннан, әлеге компания кыш көне Югары Ослан – Аракчино боз кичүе өчен җавап бирә. Кама Тамагы, Тәтеш, Югары Ослан якларына Казаннан кайтучылар өчен кичү аша чыгу шактый вакытны янда калдырырга, юлны кыскартырга мөмкинлек бирә. Бакчачылар өчен паром ачылу аеруча кулай булган.

– Кыш көне боз кичүе эшләгәнне күреп: «Эх, ник җәен дә паром ачмыйлар икән монда», – дип уйлый идем. Югары Осланда бакчам бар. Җәй көне еш кайтырга туры килә. Машина белән кайту сәгатьтән артыкка сузыла. Хәзер 20 минут эчендә бакчада булабыз. Әйтик, Аракчинодан Югары Осланга машина юлы аша кайтсаң, 51 чакрым узарга туры килә, ә кичү ачылганнан соң юл 8,5 чакрымга кадәр кыскарды, – ди газета укучысы Фәрит Насыйров.

Паром белән җәяүлеләр дә чыга икән. Туристлар да очрый, диләр. Идел буйлап чыкканда, матур табигать күренешләре ачыла, Барлык диннәр гыйбадәтханәсе якыннан күренә.

Паромлы кичү көн саен иртәнге 6дан төнге 12гә кадәр эшләячәк. Идел буйлап 20 минут аралык белән барлыгы өч паром йөри. Тиздән дүртенчесен дә өстәргә җыеналар. Бер паромга барлыгы 14 җиңел машина сыя. Әлегә зур чиратлар күзәтелми. Паромлы кичү аша чыгу бәясе – 250 сум. Йөк машиналарына әлегә паромлы кичү аша чыгарга рөхсәт ителми.

# Сабан туен үткәрмичә ярамый

МИЛЛИ БӘЙРӘМ

**Июль – Сабан туйлары ае. Авылларда шау-гөр килеп бәйрәмгә әзерләнәләр. Бизәлгән атлар, гармун тавышы, чигүле сөлгеләр, җыр-бию, уен-көлке… Электән килгән гореф-гадәт – Сабан туе алдыннан бирнә җыялар. Сөрән сугу, сөлге җыю, бирнә әзерләү, әрәпә – төрле якларда төрлечә аталса да, асылы бер.**

Бәйрәмне бу атна башында Театрлар Сабан туе башлап җибәрде. Унбер дәүләт театры артистлары җыйналып, Саба районының Лесхоз авылында бәйрәм итте. Сабан туеның абсолют батыры булып «Әкият» Татар дәүләт курчак театры артисты Юрий Чуктиев калды. Аңа Президент бүләге – машина һәм тәкә бирелде.

Казанда милли бәйрәм 15 июльгә билгеләнгән. Ә авылларда, районнарда ул бу атнада – 1, 2 июль көннәрендә гөрләячәк. 1 июль көнне кич белән исә республика халкын Саба районы Миңгәр авылы кунакка чакыра. Бәйрәм сәгать 19.00дә башланачак. Гадәттәгечә, Миңгәр Сабан туе экстрим ярышлар, әкияти салютлар, концерт-тамашалары белән кунакларны шаккатырырга җыена. Чараны Татарстанның атказанган артистлары Фәннүр Хәсәнов, Азат Зарипов һәм башка талантлы актерлар алып барачак. Сабан туенда милли уеннар белән бергә гладиаторлар ярышы, квадроциклларда, көймәләрдә узышу, ялан кул балык тоту һәм башка үзенчәлекле бәйгеләрдә көч сынашып булачак. Балалар өчен аерым мәйданчык эшләр дип көтелә. Спорт сөючеләр өчен шулай ук махсус ярышлар каралган. Үзәк мәйданда «Миңгәр» дип исемләнгән документаль фильм да тәкъдим итәчәкләр. Тамашада Татарстанның һәм Башкорстанның халык артистлары белән бергә яшь талантлар да чыгыш ясаячак. Абхазия, Бразилиядән килгән бию төркеме чыгышлары, Дагыстаннан канатта йөрүчеләрдән шоу – боларның барысын да Миңгәр Сабан туенда күреп булачак. Бәйрәмгә чит илдән, башка республикалардан да кунаклар килер дип көтелә.

baltasi.ru

### Ә СЕЗДӘ САБАН ТУЙЛАРЫ НИЧЕК УЗА?

**Марат Заһидуллин,** Чистай районы, Каргалы авылы башлыгы:

– Без 8 июльдә авыл көнен уздырачакбыз. 1 июльдә Чистайда район Сабан туе уза. Икенче көнгә шәһәрдән кайткан халык ял итә алсын өчен, бәйрәмне киләсе атнага калдырдык, Президент Указына каршы килмәс өчен, исемен алыштырдык. Авыл көне тулысынча Сабан туе рухында узачак, шул ук милли уеннар, гореф-гадәтләр сакланыр дип уйлыйбыз. Былтыр безнең районда бары Чистайда һәм Каргалы авылында гына Сабан туйлары узды. Быел башка авыллар да уздырырга җыена. Шуңа да бездә кеше азрак булыр дип уйлыйбыз. Сабан туе тулысынча иганәчеләр ярдәме белән оештырыла. Авылыбызда 2 мең кеше исәпләнә. Ярдәм кулы сузучыларга, фермерларга, шәхси эшмәкәрләргә рәхмәтлебез.

**Илсур Кәримуллин,** Кама Тамагы районы, Кариле авылы мәдәният йорты җитәкчесе:

– Көн саен район үзәгенә репетицияләргә барабыз. Кама Тамагы районы Сабан туенда быел һәр авыл китапханәсе, мәдәният йорты хезмәткәре җыештыручысыннан алып, җитәкчесенә кадәр чыгышта катнаша. Биибез, җырлыйбыз. Элек колхозлар чорында Кариле җирлегенә кергән дүрт авылны берләштергән Сабан туе гел бездә уза иде. Былтыр да оештырдык милли бәйрәмне. Быел 22 июльдә узачак авыл көне Сабан туен алыштырыр, бәлки. Ничек кенә булмасын, Сабан туе ул – татарны таныткан, дусларны, туганнарны бергә җыя торган матур бәйрәм. Аны да уздырмасак, милләтебез беткән дигән сүз. Сабан туен үткәрмичә ярамый.

# «Бәйрәм җиткәндә, йөрәк кага башлый»

Зөлфия Хәлиуллина фотосы

**Редакция шоферы – республикабыз юлларының йөзләгән чакрымнарын бергә узган хезмәттәшем Альберт Каюмовны яңа яктан ачтым. Моңарчы өч бала атасы, ярдәмчел кеше дип белә идек үзен. Баксаң, Сабан туе мәйданнарында колгага менүдә аңа тиңнәр юк икән. Дөньяга биектән карау тәҗрибәсе – 24 ел.**

– Бу – нәселдән килә, – ди Альберт. – Мин белә-белгәннән бирле әти Сабантуйларда багана башында иде. Башта егылып төшмәсен, дип куркып торуым, аннары, менеп җиткәч, бик шатланып горурлануым истә. Ул бит әтисез үскән малай. Хәзер уйлыйм да аның нигә бу шөгыльне сайлаганын яхшы аңлыйм. «Ятим булсам да, мин булдырам, менә күрегез!» – дип, бүтәннәргә дә, үз-үзенә дә исбатлаган ул, шулай итеп, холкын чыныктырган. Беренче сыйныфны тәмамлагач, мин дә тәвәккәлләп карарга булдым. Әтидән калышасым килмәде, мин дә аның улы ич! Балтач Сабан туенда беренче тапкыр менеп карадым, ләкин башта туры колгага түгел, авыш баганага. Әле дә исемдә, бик тә менеп җитәсем килде, шулкадәр халык карап торганда, җиңелеп оятка калмас өчен, бөтен тырышлыгымны куйдым. Тәки менеп җиттем. Бүләккә әтәч белән бер шешә шампан шәрабе тоттырдылар. Хәзергә кадәр аңлый алмыйм: сигез яшьлек малайга кирәкме инде ул? Әтәчне туганнарга бирделәр, аларыкы булмаган, ә шәраб кая киткәндер, белмим. Үсә төшкәч, миңа энем дә кушылды. Бу бәйрәмне безнең гаилә ел да көтеп ала. Өчебез бергәләп колгага үрмәләгән еллар да булды. Ул вакытта өч урын да безнеке була иде.

Менүен менеп була ул. Төшүе куркыныч һәм бик авыр. Аска карасаң, «беттем» дигән сүз. Берсендә бер көндә әллә ничә авыл мәйданын әйләнгәч, мин дә тиз менеп җиттем соңгы колга башына, ләкин төшәргә чамам юк. Әти карап-күзәтеп тора. Хәлемне тиз аңлады. Менеп китте дә мине җилкәсенә утыртып алып төште. Үземнең дә энекәшне шулай коткарганым булды. Роберт Миңнуллинның: «Кирәкми әтәчегез, кирәкми бүләгегез. Мине алырга гына менегез берәрегез!» – дигән шигырь юлларындагы төсле.

**– Сабантуй колгасына менү ул синең өчен нәрсә: данмы, малмы (анда бүләкләр дә саллы була), әллә инде үзең генә белгән берәр бүтән хис-кичерешләрме?**

– Баштарак бик тә эти малае икәнемне, аның шикелле үк булдыра алганымны исбатлыйсым килде. Ярыш мине ныклык, максатчанлык, кыюлыкка өйрәтте. Дөрес, бүләкләре дә күп булды. Өебез еш кына кибеткә охшап кала иде. Алары да ярап куйды. Бүген инде азарт. Булдыра алырмынмы дип, үземне сынап карау. Бик кызык бит менә. Сабан туе җитәрәк, организмым да әзерләнә башлый. Бу хакта уйласам ук, йөрәк кага башлый, уч төпләрем, үкчәләрем тирләп чыга. Шулай итеп, бөтен гәүдәм миңа булачак ярышта җиңәргә булышырга әзер торуын күрсәтә. Ташлап булмый. Әтигә әнә 56 яшь инде, ә ул узган ел багана башына менеп, юбилеена бүләк ясады. Менә алмаганнарны карап торды-торды да, йөрәге түзмәде, менеп китте.

**– Синеңчә, колгага һәркем менә аламы?**

– Теләсә, менә ала. Аннары колга озын бит ул: кем уртасына җитә, кем аны да узып китә, бик тырышлар гына иң очына барып җитә. Ләкин теләк белән генә булмый, беләк тә кирәк. Һәр иртәне йөгереп, физик күнегүләр ясамасаң, формаңны тиз югалтасың.

**– Халык: «Колгага беренче булып менүчегә җайлырак, аннары ул шомарып бетә», – ди. Син моның белән килешәсеңме?**

– Юк, беренчегә тагын да авыррак. Иске колга булса, бигрәк тә: шырпы кадалырга, ярыклары булырга мөмкин. Ә менә соңрак менгәндә, чыланып-йомшарып калган була. Иң рәхәте – кайрысы яңа гына каезланып, быел гына утыртылган яңа колгага менү. Элек саклану чаралары кулланмый гына үрмәли идек, хәзер билгә аркан урыйбыз. Ләкин хәзер катлаулырак: ярыш вакытка уздырыла. 17 метрлы колгага 17 секундта менеп җиткәнем бар.

**Йолдыз ШӘРАПОВА.**

# Салкынча җәй

**«Җәйне барыбыз да көтәбез, әлегә ул юк кына», – дип башлады «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясен Татарстанның Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе җитәкчесе Феликс Гоголь. Хәер, идарәнең метеофаразлар бүлеге җитәкчесе Ирина Трущина әйтүенчә, урамда инде җәй. Бары... салкынча җәй.**

– Температура җир өслегендә генә түгел, тропосферада формалаша. Безгә төньяк-көнбатыштан килгән салкын, юеш циклон нык тәэсир итте. Нәтиҗәдә, салкынча һава торышы торды, яңгырлар еш яуды. Ә Көнбатыш Себер якларында киресенчә, аномаль эсселек күзәтелә, – ди Ирина Трущина.

Күзәтүләр буенча, быел май, июнь айларындагы һава торышы нормадан 2-3 градуска түбән булган. Соңгы арада берничә көн яуган яңгырлар бер айлык норманы тутырган. Әйтик, Азнакай районында нормадан 3,5 тапкырга артыграк яңгыр яуган.

Явым-төшем дигәннән, күптән түгел социаль челтәрләрдә, кайбер районнарда кар яуган, дигән хәбәр таралган иде.

– Бу теоретик яктан да мөмкин түгел. 15 градус җылыда кар барлыкка килә алмый. Кайбер урында боз яуды. Бозны кар белән бутарга ярамый, кар – җәй өчен хас күренеш түгел, ә менә боз җәй көне дә яварга мөмкин, – дип аңлатты белгечләр.

Һава торышына килгәндә, бүген – пәнҗешәмбе көнне кыска вакытлы яңгырлар, төнлә 9-14, көндез 25 градуска кадәр җылы көтелә. Иртәгә явым-төшемнәрсез, коры һава торышы булачак. Температура – 19-24 градус җылы. Шимбәдән безнең республикага тагын яңа циклон якынлаша. Алдагы алты көндә һаваның уртача температурасы нормадан 1 градуска түбән, ягъни 21-26 градус җылы һәм урыны белән яшенле яңгырлар булыр дип көтелә. 6 июльдән соң һава, ниһаять, тиешенчә җылыныр һәм эссе җәй башланыр дип фаразлый синоптиклар.

Магнит давылларына килгәндә, июньдә җирнең магнит кыры чагыштырмача тыныч булды, июльдә бары өч кенә көн магнитлы булыр дип көтелә. Шуларның берсе 7 июльгә туры килә. Моны славяннарның Иван Купала бәйрәме тәэсире белән дә бәйләп карыйлар. Имеш, Иван Купала – болай да төрле мистик күренешләргә бай Кояш бәйрәме, үз чиратында, җирнең магнит кырына да йогынты ясаячак. Ничек кенә булмасын, бу көннәрдә йөрәк-кан тамырлары авырулы, кан басымы тотрыксыз булган кешеләргә сәламәтлегенә карата игътибарлы булу сорала.

# Мунча себеркесен – 15 төрле үләннән

**Мунча себеркесен Биектау районының Ямаширмә авылында яшәүче Рашат Кәлимуллин кебек бөтен шартын китереп, оста итеп бәйләүче юктыр ул. Бер себеркене ярты сәгать бәйлим, аңа 15 төрле үлән дә кушып җибәрәм әле, дип, бик тәмләп сөйли ул. Себерке әзерләгәндә дару үләннәрен генә түгел, карлыган, алмагач, миләш ботакларын да эшкә җигә.**

– Мунча себеркесен каен агачы ботакларының иң башындагы яфрагы башкалары зурлыгында булгач җыярга кирәк, әлегә ул кечкенәрәк. Июль айларының урталарына өлгерер дип уйлыйм. – ди Рашат. – Яфракның зурайганын көтмәсәң, ул кипкәч кыürылып килә дә коела. Себеркегә дигән ботакларны 12-20 еллык каеннан җыям. Һәр агачтан берничә генә ботак алам. Аларның да матурларын, берничә ботакчык чыгарганын сайлыйм. Алып кайтуга ук бәйләп куймыйм, югыйсә аның эче яхшылап кипмәскә, күгәрергә мөмкин. Караңгы урынга көлтәсе белән генә дүрт-биш көнгә киптерергә куям. Аннары, өстен бастырып, салкынча караңгы урынга алып куям. Алмагач, карлыган, миләш, баланның кирәкмәгән, калынрак ботакларын да кисеп алып киптерәм. Ромашка, бөтнек, мәтрүшкә, меңъяфрак үләннәрен, имән, өрәңге агачы ботакларын кыстырып бәйлим. Өлгергән берсен җыеп киптереп барам.

Себеркеләрне исә көз җиткәч, октябрьләрдә генә бәйли икән. Бер себерке бәйләү өчен ярты сәгать вакыты китә. Көнөнә унлап себерке әзерли. Аларны да, үзе әйтмешли, аппетиты килгән саен, телевизор карый-карый гына бәйли. Сихәте булсын өчен, догалар да укып куя икән. Шул рәвешле, бер елга өчәр йөз себерке әзерли. «Аларның яртысын үзем кулланам, мунчаны бик яратам, көн дә диярлек ягабыз», –ди. Калганын бүләккә, күчтәнәчкә бирә, кибеткә сатарга куя.

Рашаттан себеркене дөрес итеп пешерү серен дә сораштым.

– Газ өстендә суны кайнатам да тазга салам. Шуңа себеркене батырып, өстен каплап, ун минут тоттәм. Башта шуның исен иснәп утырасың, суын таш өстенә дә сибәсең. Мунчага хуш ис тарала. Себерке төнәткән су белән авызымны да чайкыйм, өстемә дә коям. Тулы бер сәламәтләнү процедурасы була инде. Шыбыр тиргә батып чабынгач, кышын тәнемне кар белән ышкыйм, җәен салкын су белән коенам. Мунчадан чыккач, төрле үләннәрдән кайнаткан чәен дә эчәбез. Бигрәк тә иван-чәйне яратабыз. Бездә үскән һәр үләннең сихәте бар, куллана белергә генә кирәк, – ди мунча яратучы Рашат.

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.**

**Бу юлы авылга кайтканда, урман кырыйларында туктаган машиналарга күз төште. Былтыр каен җиләге 13 июньдә үк өлгергән булса, быел әле ул шау чәчәктә. Июнь азагында урманда тагын нәрсә эшләп була икән дисәм, гөмбә җыя икән халык. Каен гөмбәсе бик күп, ди. Кайберәүләр мунча себеркесе әзерли башлаганнар. Урманның байлыгы җитәрлек җитәрлеккә, тик талпаннар, еланнар күп дип зарланучылар да бар.**

# Урманнарга керсәң, сызгырып кер

*✓ Татарстан Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белгечләре, урманда адашмас өчен, кайбер кагыйдәләрне истә тотарга куша:*
*✓ Урманга барыр алдыннан маршрутны ныклап уйлагыз.*
*✓ Туганнарыгызга кая барасыгызны әйтеп китегез.*
*✓ Кесә телефонын онытмагыз.*
*✓ Урманга киткәндә, ашамлык һәм эчемлек, пычак, шырпы кебек кирәк-яраклар да алырга кирәк.*
*✓ Адашсагыз, «112» бердәм ашыгыч хезмәт номерын җыегыз.*
*✓ Адашканда караңгыда йөрмәскә, хайван эзләре буенча бармаска, сазлы, бака тәңкәсе белән капланган урыннарга кермәскә киңәш ителә. Автомобиль, локомотив гудоклары тавышлары ишетсәгез, шул якка барырга тырышыгыз.*

### ТАЛПАН

Быел Россиядә, талпан тешләп, меңгә якын кеше боррелиоз йоктырган, дип хәбәр итә Роспотребнадзор. Талпаннар 7-22 градус җылы булганда аеруча яхшы үрчи, катнаш урманнарда күп очрый, бигрәк тә сукмак тирәләрендә. Белгечләр әйтүенчә, урман бете кеше исен 10 метрдан сизеп ала. Гадәттә, йомшак урынга (култык асты, чәч арасы, колак арты) кадала. Талпан тешләгәне беренче сәгатьләрдә сизелми. Соңрак кадалган урын түгәрәкләнеп, кабарып чыга. Талпаннардан, башка төр бөҗәкләрдән саклану өчен урманга тиешенчә киенеп барырга кирәк. Өс киеме бөтен җирне дә каплап торырлык булсын, якаларны төймәләргә, күлмәкне – чалбарга, чалбарны итек эченә тыгарга, башлык киярге киңәш ителә.

### ЕЛАННАР

Кара еланнар безнең урманнарда еш очрый. Әле менә шушы көннәрдә генә Яңа Чишмә районының Екатерина Бистәсе авылында еланнар аеруча котырды, дип шалтыраттылар. Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белгечләре, авыл территориясен тикшереп, халыкка еланнардан саклану чаралары хакында сөйләп тә кайткан. Биология фәннәре докторы Илгизәр Рәхимов әйтүенчә, еланнар беркайчан да үзләре һөҗүмгә ташланмый. Җиләк, гөмбә җыйганда, кеше, ялгыш, еланга басса, ул, сакланып, чагарга мөмкин. Кара еланны үтерергә ярамый, алар Кызыл китапка кертелгән.

Еланнардан саклану өчен аякка резин итек кияргә кирәк. Резин галош, итек аркылы елан тешли алмый. Елан очраса, аңа узып китү мөмкинлеге бирегез, таяк белән төртергә, куркытырга ярамый.

### АЮ

Татарстанның хайваннар дөньясын саклау һәм файдалану идарәсеннән алынган мәгълүматлар буенча, хәзерге вакытта республикада барлыгы 100гә якын аю санала. Аларның күбесе Яшел Үзән, Мамадыш, Саба, Кукмара, Балык Бистәсе урманнарында очрый. «Татохотрыболовобщество» иҗтимагый оешмасы рәисе Илһам Садыйков әйтүенчә, безнең урманнарда аюлар үрчер өчен уңай шартлар тудырылган, шуңа да аларның саны ел саен 1,5 тапкырга артыга мөмкин. «Аюга зыян салмасаң, ул да сиңа ташланмый. Ана аю, балаларын саклау максатыннан, һөҗүм итәргә мөмкин», – ди Илһам Садыйков. Аюларны атарга ярамый, моның өчен хәтта җинаять җаваплылыгы да каралган, чөнки алар Кызыл китапка кертелгәннәр. Аю күрсәң, качу ягын карарга кирәк, әмма йөгерергә ярамый. Аю сезне күреп алган икән, сызгырып, тавыш чыгарып куркытырга була. Шулай ук «үлгән» булып кылануның да файдасы бар, ди белгечләр.

**Эльвира МОЗАФФАР.**

# Буй җитмәгән җиргә хыял җитә

Үтеп барышлый

Равил САБЫР

**Машинаны яңарттым. Кроссовер сатып алдым бу юлы. Карап торышка бик кәттә, «крутой» машина үзенә күрә. 21 елга алтынчысы инде монысы. Туза башлагач, искесен сатам да, банк биргән кредит акчасын өстәп, яңасын алам. Хәер, күпчелек кеше шулай итә инде, тик барысы да түгел.**

Яңа машинага утыргач, 10-15 еллар элек булган хәл искә килеп төште. Ул чакта «Вечерние Челны» газетасында ике Сергей белән бер кабинетта утырып эшләргә туры килгән иде. Берсе пеләш, ак чәчле һәм ак мыеклы иде, икенчесе озын кара чәчле иде. Без өчәүләп аратирә тәмәке көйрәтергә чыккалый идек. Берсендә шулай авыздан төтен болытлары өреп гәпләшеп торабыз, зур гына, бик кыйбатлы бер машина килеп туктады. Безнең күзләр шул мунча хәтле япон автомобилендә.

«Иртәме-соңмы, мин дә шундый машина алам, – дип куйдым мин. – Хәер, миңа мондый үк зурысы кирәкми, бер кечкенә генә джипчик та җитә».

Ике Сергей да рәхәтләнеп, чын күңелдән көлделәр инде миннән. Янәсе, кая инде ул безләргә мондый машиналар алу.

«Әйдәгез алайса, – мин әйтәм, – бәхәс?! Бер-ике елда гына димим, бәлки, ун ел узар, бәлки унбиш, тик мин барыбер үз максатыма ирешәчәкмен!»

Риза булмадылар. Имеш, унбиш елдан кем була да, кем булмый. Чыннан да, ак чәчле Сергей дүрт ел элек бакыйлыкка китеп барды, урыны җәннәттә булсын. Соңгы бер-ике елында «Ока»да йөрде, кара чәчле Сергейның әле һаман да машинасы юк.

Аллаһы Тәгаләне көлдерәсең килсә, аңа үзеңнең планнарың турында сөйләп бир, дигән гыйбарә бар. Аңлавымча, аның мәгънәсе болай: Ходай синең белән алга таба ни буласын сиңа караганда күбрәк белә, шуңа күрә максатларың аңа көлке тоелырга мөмкин. Ләкин бу бит әле кеше план-максатларсыз яшәргә тиеш дигән сүз түгел. Киресенчә, кеше үз алдына мөмкин булганча һәм хәтта мөмкин булмаган зур максатлар куярга тиеш, минемчә. Ә иң мөһиме – моның белән генә чикләнмичә, аларга ирешү өчен, бар көчен биреп тырышырга тиеш.

Ә зур максатлардан бер дә курку кирәкми. Мәсәлән, мин авыл мәктәбен тәмамлаганда, Казан университетына укырга керәм дигәч, көлүчеләр дә булмады түгел, булды. Имеш, кая инде ул сиңа анда уку, сине ишектән дә кертмиләр бит, лутчы Минзәләгә барып сварщиклыкка укы, акчалы эшең булыр, ичмасам. Ә мин бардым да кердем университетка.

Урысча яза башлагач та, төрттерүчеләр табылды. Янәсе, син хәзер генә, татар матбугатында гына беренче ракеткалар исәбендә йөрисең, ә анда синдәйләр буа буарлык, шулар арасында батып кына калачаксың. Бер дә батмадым да, югалмадым да. Шәһәр һәм республика күләмендә уздырылган әллә ничә конкурсның җиңүчесе дипломнары һәм кубоклары бар.

Драматургиягә кереп киткәч тә, елмаеп караш ташлаучылар булмады түгел. Имеш, ул бит сиңа гәҗиткә мәкалә язу гына түгел, әдәбиятның иң катлаулы жанры, әнә кайбер олы-олы язучыларның да драматургиядә берни дә килеп чыкмады, ә син кая тыгасың борыныңны? Ә мин тыктым һәм Аллага шөкер, пьесаларым куелды, кайберләре һаман да уйналып тора.

И мактанасың инде рәхәтләнеп, дисәгез, психотерапевт Валерий Синельниковның «Чиреңә гашыйк бул» («Возлюби болезнь свою») китабыннан бик кызыклы бер мисал китерәм. 90нчы елларда, илдә икътисади кризис котырганда, 40 яшьтән узган ике ир-ат, гаилә башлыклары, шактый авыр хәлдә кала: алар эшләгән завод берничә ай буена хезмәт хакы түләми. Беренче ир гәҗитләрдән игъланнар укып карый да (ә анда 40 яшькә кадәр генә хезмәткәрләр кабул итәбез дип язылган була), язмыштан узмыш юктыр инде, мине кем кая алсын, бу эшемнән дә колак кагармын дип куркып, акча түләмәгән эшенә йөри бирә.

Икенчесе үзенең белеме һәм осталыгы барыбер кемгәдер кирәк икәненә ышана. Ул бер бит кәгазь һәм каләм алып, аена ничә сум хезмәт хакы кирәклеген исәпләп чыгара. Бу суммага гаиләсен ашату-эчертү, киендерү, коммуналь хезмәтләр, телефон өчен түләү, җәй көне җылы якка ялга барып кайту – кыскасы, бөтен чыгымнарын да кертә. Килеп чыккан суммадан башта үзе дә куркып кала. Аннары: «Туктале, шулкадәр үлеп китәрдәй акча түгел ич инде бу?! Моннан күбрәк алып эшләүчеләр бар бит», – дигән нәтиҗәгә килә.

Шулай итеп, ул үзенә яхшы хезмәт хакын вакытында түли торган эш эзли башлый. Бер атна чамасы да узмый, урамда күптән күрешмәгән дустын очрата бу. Хәл-әхвәлләр турында сөйләшә башлагач, үзенең яңа эш эзләвен, нинди хезмәт хакы кирәклеген әйтә. Баксаң, дустының танышы яңа предприятие ачып йөри һәм аңа нәкъ менә шундый белгечлеге булган хезмәткәр кирәк икән. Хезмәт хакы күләме дә нәкъ теге кәгазьдә язылган кадәр!

«Бу әкият түгел, тормыштан алынган мисал, – дип яза китап авторы. – Очраклылык, дисезме? Ләкин очраклылык – ул бит аң төпкелендә урын биләп торучы закончалык. Беренче иргә теләгән эшен табарга үзе үк программага салып куйган уй-шикләре комачаулаган, ә икенчесе үз-үзенә, белеменә, тәҗрибәсенә нык ышанган һәм һәркайсы ни көткән, шуңа ирешкән. Без бит үз тормышыбызны үзебез корабыз. Безнең язмыш – ул безнең уйларыбыз».

…Бик кечкенә чакта, әле балалар бакчасына йөргәндә, кайбер кызлар миннән: «И-и-и, бигрәк хыялый инде син!» – дип көлә торганнар иде. Әйе, бала чактан ук хыялланырга ярата идем, хәзер дә алга бик зур планнар корып яшим. Аллага шөкер, бик күбесе тормышка ашып бара. Сез дә хыялланырга курыкмагыз! Хыялсыз кеше – канатсыз кош. Уңышлар сезгә!

# Куанычлы ачыш

**Укырга омтылган яшьләрне күргәч, ирексездән, үземнең дә институтка кереп йөргән чаклар искә төшә. Дөрес, югары уку йортында укырга мөмкинлек биргән сынау диңгезен мин үзем тыныч йөзеп чыктым.**

Ят җирдә, ят телдә имтиханнар тапшырсам да каушамавым – безнең белән чиләнгән мөгаллимнәребезнең тырышлыгы нәтиҗәсе иде, әлбәттә. Төпле белем бирү белән бергә, алар безне төрле дәрәҗәдә уздырылган олимпиадаларда катнаштырырга тырышалар иде. КАИны да мин Казанга республика олимпиадасына килгәч сайладым.

Институтка керү имтиханнарын тапшырырга килүгә, яңа дөнья белән очраштым. Бар да гаҗәп иде. Яңа кешеләр һәм, гомумән, яңа дөнья иде бу. Биниһая зур илнең кайсы төбәкләреннән генә җыелмаганнар иде данлыклы уку йортына. Казанны бөтен Союз белә икән ләбаса! Тулай торактагы бүлмәбездә дә, танышкач, дүртебезнең дүрт яктан булуыбыз ачыкланды. Әле бер иптәшебез әнисе белән килгән иде. Бусы мине отыры гаҗәпләндерде. Бездә моны күрсәләр… И-һи, буйга үскән егетнең әнисе итәгенә тагылып йөрүен белсәләрме… Һичшиксез, аны җир тишегенә кертердәй итеп, ачы көләрләр иде безнең малайлар. Хәер, бүлмәбездә канәгатьсез сүз ишетелмәде, киресенчә, уңайга үзгәрде фикеребез: иртә-кич чәй әзерләп, бүлмәдә тәртип тотуны үз кулына алды ич хуҗабикәбез. Алга китеп әйтим, аның малае бу факультет бәйгесеннән узарлык балл җыя алмады, әмма төшеп калмады. Мөгаен, әнисе киңәш биргәндер: гаризасын түбәнрәк балл яраган икенче факультетка үзгәртеп язып, студент булды.

Беренче көнне үткәрелгән математика буенча язма имтиханында ук «икеле» алучылар байтак булды. Тулай торакның без урнашкан өченче катында да шактый күренде андый бәхетсезләр. Билгеләр язылган кәгазь кабул итү комиссиясе ишегенә эленгән көнне өченче катыбыз тынып калды. Кичкә таба гына коридорда ниндидер көньяк республика егетләре төркеме гөрләп йөрде. Икенче көнне кич шуларның берсе, мине эзләп, бүлмәбезгә килеп кермәсенме!

Билгене гадел куймаганнар, дип, институт башлыгының үзенә үк барып җиткән бу. Ректор кабул итү комиссиясе рәисен чакырткан һәм җыйнаулашып безнең эшләрне караганнар. Егетнең кызыл каләм белән куелган сорау билгеләре мыжлап торган җавапларын күргәч, сүзсез дә аңлашыла, дип, җитәкче абзый аны борып чыгарырга теләгән. Әмма теге үзенең җитешсезлекләрен бөтен милләт вәкиле булуы белән аңлатып карышкан. Шунда, татар авылы мәктәбендә укыган кешенеке дип минем җавапларны күрсәтеп, теге союздаш республика вәкиленең авызын томалаганнар.

Ректораттан кайтышлый аптырап кергән икән минем янга. Мин аңа мәсьәләсенең чишелеш серләрен күрсәткәч, ул:

– Ничек болай җиңел генә чишәсең соң син шундый катлаулы мәсьәләне? – диде, исе китеп.

– Бездә математиканы Нера Ахметовна үзе укытты бит! – дидем мин шулчак аңа.

Ничектер үзеннән-үзе килеп чыкты мөгаллимәбез исеме. Безнең авыл мәктәбе укытучысын бу ят егет белми, әлбәттә. Ә бит чыны – шул!

Техник вузга керсәк тә, рус теленнән дә имтихан бирергә тиеш идек әле без. Мине таң калдырган тагын бер көтелмәгән хәл булды шунда. Милли мәктәпләрдә белем алган абитуриентларны изложение язарга бүтән аудиториягә чакырдылар. Әлеге бүлмә янына килсәм, ишек төбендә шактый гына кеше җыелган һәм алар, ни күрим, рәхәтләнеп русча сөйләшәләр иде. Менә сиңа бүтән милләт мәктәбе укучылары! Соңыннан белдем, союздаш республика вәкилләре башка телдә укыган булып исәпләнәләр икән. Әлбәттә, алар шәһәрнекеләр һәм рус телен яхшы өйрәнгәннәр… Шунда берсе бу фәннән кемнең нинди билгеләргә укуын сорашып чыкты. Ул аны, шаяртып, кызык өчен генә сорашты кебек үзе. Минем билгеләрне ишеткәч, сине алгы урынга утыртабыз, диде. Һәм шулай килеп чыкты да. Мин кергәндә, бүтән урыннар калмаган иде инде, беренче өстәлгә утырырга туры килде. Имтихан алучы текстны укып чыкты да, тәмәке тартып керәм, дип, бүлмәдән чыгып киткән иде, бер сәгатьтән артык югалып торды. Дөрес, бу сынау билгесе бәйгедә исәпкә алынмый, шулай да «икеле» алу да килешми. Булдыра алганча тырыштым. Алда утыруның үзенчәлеге шул икән: күбесе мөстәкыйль язасы изложениесен миннән күчереп алды. Төрлесе төрлечә, билгеле. Кайсысы аерым сүзләрнең язылышын сораша-сораша теңкәмә тиде, кайсысы язмамның теге-яки бу өлешен күрсәтүемне үтенде, кайсысы турыдан-туры күчереп язды… Мондый әрсезлекне дә тәүге тапкыр очратуым иде әле минем.

Имтиханнан чыккач, теге егет мине куып җитте дә:

– Син үзең русча начар сөйләшәсең, ә изложениене шәп яздың һәм мәгънәле итеп! – дип, язмам белән соклануын белдерде.

Тагын шунысы истә калган. Тулай торакта бергә яшәгән бүлмәдәшләрем белән дусларча җылы аерылыштык. Югыйсә, танышу авыр барды. Мин – авылдан, ә күршеләрем – зур-зур шәһәрләрдән килгән ыспай-матур киенгән егетләр. Шуңа өстәп, коточкыч акцентым да мине кызарта, иркен аралашырга аяк чала бит әле. Хәер, беренче имтихан билгесе беленүгә, мин үземә булган карашларының үзгәрүен сиздем. Кемгә карап каршы алсалар, белем – акылга карап озаталар, дигәннәрме әле…

Ильяс САЛИХҖАН.

БӘХИЛЛӘШҮ

**22 июнь көнне, каты авырудан соң, «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире, татар матбугаты үсешенә бәяләп бетергесез зур өлеш керткән шәхес, күп татар журналистларының остазы Исмәгыйль Шәрәфиев арабыздан китеп барды. Ул әлеге басманы 27 ел җитәкләде...**

**Исмәгыйль Сәлмән улы Шәрәфиев 1950 елның 12 ноябрендә Казанда туа. Казан дәүләт университетын тәмамлагач, хезмәт юлын «Социалистик Татарстан» («Ватаным Татарстан») газетасында башлый. Төрле елларда «Татарстан яшьләре» газетасында тәрҗемәче, хатлар бүлеге җитәкчесе, җаваплы сәркатип, редактор урынбасары була. «Идел» журналының җаваплы сәркатибе булып эшли. 1990 елда «Татарстан яшьләре»нең баш мөхәррире итеп билгеләнә. 2017 елда аңа «Бәллүр каләм» республика бәйгесенең иң зур бүләге – «Лада Калина» автомобиле тапшырылды.**

**Исмәгыйль Шәрәфиев әнисе һәм әбисе кабере янәшәсендә – Әтнә зиратында җирләнде.**

# «Мин – Исмәгыйль Шәрәфиев укучысы»

Исмәгыйль абый китеп барды...

Мәңге шулай булыр иде кебек: иң зур тиражлы «Татарстан яшьләре» һәм иң шәп мөхәррир Исмәгыйль абый Шәрәфиев. Балачактан шуны күрепукып, шул дулкында үскәнгә, бу инде традиция кебек кабул ителә. Көн дә ашарга кирәк булган кебек, ярты ел саен «Татарстан яшьләре»нә язылу да гадәти хәл. Аның мөхәррире дә башка була алмый: әлеге газета башында Исмәгыйль Шәрәфиев кенә булырга тиеш кебек иде. Иде...

2016 елның сентябрендә булган соңгы сөйләшүебез, кайтаваз булып, колакта яңгырый. «Ниндидер үзгәреш кирәк, менә шул хакта уйлап йөрим», – диде Исмәгыйль абый. Бу сүзләрне әйткәнче, ул гына булдыра алганча, бөтен нәрсәне җентекләп сорашты: безнең редакциядә журналистларның хезмәт хакы күпме, гонорар ничек исәпләнә, фотограф бармы һәм башкалар... Мин бик дулкынландым: Сәлмәнеч хәтле Сәлмәнеч синең эшне ничек оештыруың белән кызыксынсын әле! Гомумән, Исмәгыйль абый бөтен нәрсәне җентекләп, төбенә төшеп сорашырга ярата иде. Материал язасың икән, язганнан кала да аңа бөтен нәрсәне яңабаштан бөртекләп сөйләп чыгарга кирәк. Ә «вдруг» син берәр нәрсәне онытып калдырган булсаң?! Каршына утырып, язганыңны синең белән бергә укый. Каршында ук төзәтә. Тик синең иҗат кешесе һәм нечкә күңелле булуыңны яхшы белә, шуңа күрә сызу-бозуларны да бик нечкә итеп башкара, син үзеңнең язмаңның тагын да шомарганын күреп сөенәсең, өйрәнәсең, яхшырак булырга омтыласың. Һәм күңелдә гомер буе озатып барырлык бер сабак кала: «Ә Исмәгыйль абый бу очракта нәрсә әйтер иде?»

«Исмәгыйль абый нәрсә әйтер иде?» дигән әйбер Исмәгыйль Шәрәфиев кул астында эшләгән һәркемгә таныш хистер дип уйлыйм. Университетның журналистика факультетының ролен һич тә киметәсем килми, әмма чын журналистларны бездән Исмәгыйль Шәрәфиев ясады. Белемең дә, дипломыңның төсе дә, яшең дә роль уйнамый иде бугай аның өчен. Аз гына талантың бар икән, ул сине үстерәчәк. Исмәгыйль Шәрәфиев – тулы бер буын татар журналистларын тәрбияләгән, рәсми рәвештә булмаса да, үз мәктәбен булдырган кеше. Аның мәктәбен узгансың икән, димәк, син укучыга якынрак буласың, димәк, син һәр җөмләңне «Тукта, укучы минем нәрсә язганымны аңлармы? Нәрсә әйтергә теләдегез дип редакциягә шалтыратмасмы?» дип уйлап язасың (монысы да аның сүзләре). Аның мәктәбен узгансың икән, димәк, син җирдә аунап яткан таш кисәгеннән дә фәлсәфә чыгара белергә тиеш. Бер җөмләңне дә, узар әле, дип яза алмыйсың, чөнки газета битенә салынасы һәр язманы ул үзе укый! Вакытын да таба, мөмкинлеген дә. Аның кебек башка мөхәррирләр булдымы икән? Әлбәттә, тәҗрибәм дә, яшем дә кимнеңдер эшенә бәя бирерлек түгел, әмма мин Исмәгыйль Шәрәфиевне заманыбызның иң саллы мөхәррире дип саныйм. Аның кебек сүзне кадерләгән, укучыны хөрмәт иткән, басма матбугатны яраткан, кул астында эшләгән һәр кешене шәхес итеп күргән тагын кем бар икән? Ул бик үзенчәлекле иде һәм шул үзенчәлеге белән бөек иде!

Аның эшкә карата булган бөтен вакчыллыгы, таләпчәнлеге артында искиткеч нечкә күңелле кеше ята иде. Аталарча кайгыртып, авырып китсәң, һәркөнне хәлеңне белешеп тора. Бөтен гаиләңне белә. Авыр чагында мәзәк сөйләп булса да елмайта, ә мәзәгенең төбендә тормыш мәгънәсе ята, шуңа төшенеп, кайгыруың буш булганны аңлыйсың... Журналистика гына түгел, тормыш мәктәбе дә булды шул Исмәгыйль абый кул астында эшләү...

Һөнәрең шундый булгач, төрле кешеләр белән очрашырга, төрле темаларга язарга туры килә, әмма бу кыска гына язмадан да авыррак әйбер язылганы булмады. Чөнки нинди генә сүз язсам да, ул Исмәгыйль абыйның бай күңелен, гаҗәеп шәхесен, искиткеч талантын ачарлык түгел кебек... Бер нәрсәне төгәл әйтә алам: еллар узган саен, «Мин «Татарстан яшьләре»ндә эшләдем, мин – Исмәгыйль Шәрәфиев укучысы» дигән горурлык арта гына барачак. Һәм яшәгән саен, зуррак җаваплылык өстәячәк. Мин бит Исмәгыйль Шәрәфиев укучысы!

**Гөлнара САБИРОВА,**
«Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррире.

**Студент чакта Исмәгыйль абый белән танышкач, ул миңа заманча, затлы кеше итеп күзалланды. «ТЯ»да башка хезмәткәрләр дә төшеп калганнардан түгел үзе, әмма Исмәгыйль абый заманыннан бер адым алдарак бара торган кеше сыман тоелды миңа. Бу аның сөйләмендә дә, үз-үзен тотышында да, вак шакмаклы күлмәгендә дә, портфель һәм кәнәфиендә дә чагыла иде, ләкин ул беркайчан тәкәббер булмады.**

# «Телисеңме-теләмисеңме, ә теләргә кирәк!»

Без ул вакытта бала-чага, әмма ул, яшьләр газетасын чыгаргангамы (ул чакта «ТЯ» чыннан да яшьләр газетасы иде), безне бала-чага итеп күрмәде.

Кемнән генә сорама, барысы да Исмәгыйль абыйның нечкә юмор хисен искә ала. Ул сиңа нәрсәнедер җитди кыяфәт белән сөйли башлый, ә син аның шаяру икәнен бишенче җөмләсеннән генә аңлыйсың. «ТЯ»да эшләүчеләр ул яктан тәҗрибәлерәк, өченче җөмләдән үк аңларга мөмкиннәр. Редакциядә һәрвакыт җиңелчә, шаяру-елмаюлы атмосфера хөкем сөрде. Шулай үпкәсез, интригасыз эшләгәндә генә 200 меңнән артык тираж белән газета чыгарып буладыр. Коридорда игъланнар тактасында әле дә зур хәрефләр белән «Телисеңме-теләмисеңме, ә теләргә кирәк!» дип язылган. Бу нәкъ «Татарстан яшьләре»чә! Нәкъ Исмәгыйль абыйча! Кара юмор да ишетеп була иде редакциядә. Ялга китәсе хәбәрчегә «андый-мондый була калса, некролог өчен фотоңны калдырып кит» дию мондa гадәти хәл. «Татарстан яшьләре»нең соңгы битендә һәрвакыт юмор һәм сатира басыла. Һәм бу битне баш мөхәррир берәүгә дә ышанып тапшырмый иде, һәрвакыт тәмләп үзе эшләде. Белүемчә, үләре алдыннан Исмәгыйль Шәрәфиев бик күп номерга җитәрлек язма әзерләп калдырган.

Исмәгыйль абыйны яратып искә алучылар аның тагын бер сыйфатын ассызыклый. Ул беркайчан, мин – җитәкче, дип тавышын күтәрмәде, кычкырмады. Студент чакта, сер түгел, яшь журналистлар үз язмаларын берьюлы төрле редакциягә бирә. Мин дә шулар рәтендә. Гонорар эшлим дип түгел инде, берсе булмаса, икенчесе чыгарыр дип. Исмәгыйль абый моны белеп алды да миңа шелтә белдерер урынына әйтеп куйды: «Маладис! Яңгырлар кебек, бер әйберне ике тапкыр сатарга кирәк». Шулай юмор белән тәрбияли иде ул.

Кеше китә – җыры кала, диләр. Бу сүзне, гадәттә, җырчылар, язучыларга карата әйтәләр, чөнки алардан иҗат әсәрләре кала. Исмәгыйль абыйдан исә «Татарстан яшьләре»н укып үскән берничә буын татар калды. Менә ул аның «җыры». Кызганыч, дөнья шулай яратылган. Беркем дә, бернәрсә дә мәңгелек түгел. Исмәгыйль абый әйтмешли, телисеңме-теләмисеңме...

**Данил СӘФӘРОВ,**
«Татарстан яшьләре»ндә берничә ел «Тамаша» сәхифәсен алып баручы.

# Ишегалдын әкият иткәннәр

Балтач районына сәфәргә баргач, Арбаш авылына да кереп чыгарга туры килде. Журналистлар икәнебезне белгәч, Арбашның күршесендә генә урнашкан Карадуган авылы кешеләре мине, Зиннәтуллиннарга кермичә китеп барма тагын, ишегаллары чын җәннәт инде менә, дип озатып калды. Аларның ишегалды искитмәле, бер керсәң, чыгасы да килми, дип, бер-берсен бүлдереп сөйләп алдылар. Сүзләре хак булып чыкты: ишегалдын гөлбакча иткәннәр. Түрдә пальмалар үсеп утыра, аның ышыгында сине негр кызы сәламли. Эт тә оясыннан чыгып, кояш астында изрәп ята, арбасына гөл чүлмәген утырткан ат каядыр ашыга. Чыршы, туя агачы төпләренә керпеләр иләшкән. Эскәмия астында еланнар шуыша. Ул да түгел, юлыңа пингвиннар килеп чыга, тәвә кошы, павлиннар да бар икән әле монда. Ясалма күлдә үрдәкләр йөзә. Ишегалды буйлап йөри торгач, урамда җәй дими үсеп утырган гөмбәле аланга да килеп чыгасың. Боларның барысын да Әлфия апа белән Фаяз абый пластик шешәләрдән һәм цементтан катырып эшләгән.

– Баштарак бу эшкә ирем Фаяз тотынды, мин дә кызыгып киттем. Пенсиягә чыккач, вакыт та күбәйде. Эшкә өйрәнгән куллар тик тора белми, нәрсә эшлим икән, дип, кычытып кына торалар. Улыбыз Рүзәлгә дә йокты бу шөгылебез. Ул тегермән, кое, беседка, чәй эчәргә түгәрәк өстәл, шашлык пешерергә мангал эшләп куйды. Оныкларга күңелле булсын өчен дип тә тырышабыз инде. Урманнан балалар җыелышып керә, көне буе шушында уйныйлар, монда рәхәт, диләр. Аларга карап, без дә сөенәбез, – ди Әлфия апа.

Вәли үз эшендә, Гали үз эшендә дигән кебек, Зиннәтуллиннар гаиләсендә эш бүленгән. Әлфия апа бакча, ишегалды өчен җавап бирсә, Фаяз абый – теплица хуҗасы. Иртә яздан теплицага кыяр, помидорлар, кавын-карбыз утыртканнар. Кыярлары апрельдә үк өлгергән инде. Үсеп утырган карбызларына карaганда, тиздән анысы да өлгереп җитәргә охшаган.

Хуҗалыкларында сыер, бозау, кош-корт: каз, үрдәк, тавыклар да асрыйлар. Анысы – уллары Рүзәл һәм киленнәре өстендә.

– Кырын ятып әвен сугып булмый, диләр түгелме?! Ялкау булсаң, авылда яшәп булмый. Үзебезчә шулай тырышып яшәп ятуыбыз инде, – ди Зиннәтуллиннар.

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА,**
Балтач, Арбаш.

Автор фотолары

# «Сәламәтлегенең кадерен белгән кеше пластик тәрәзә куйдыртмый»

ОСТА

**Тәрәзәләр – өйләрнең күзләре кебек. Аларга карап кына да йортның хуҗалары турында әллә ни чаклы мәгълүмат алып була. Кайчакта бу йорттагыларның нинди кәеф белән яшәүләрен дә тоясың сыман. Элегрәк әбиләр дә, бала күзсенеп еласа, догалар укып, балаларның битләрен тәрәзә рамын сөрткән су белән сыпырырлар иде. Ни гаҗәп: файдасы тия, бала борчылып, бәргәләнеп елаудан туктап, йоклап китә. Ә инде тәрәзә рамнарын, аның йөзлекләрен ясаучылар һәр авылда берничә генә һәм алар һәрвакыт кадер-хөрмәттә була торган иде.**

Автор фотосы

Моннан җиде-сигез ел элек безнең яшәешебезгә пластик тәрәзәләр килеп керде. 25 ел хезмәт итә, буйыйсы, карыйсы юк, имеш. Киләләр, үлчәмен алып китәләр дә, берәр көннән янәдән килеп, тәрәзәләрне алмаштырып та куялар. Бу яңалыкка 25 ел үтмәде, шулай да һәр әйткәннең чын түгеллеге инде күренә башлады. Тәрәзә пыяласы белән пластик рамнарны тоташтырган резиналар туза, һава йөри башлый. Пластикларның да төрлесе бар икән, кайберләре формасын югалта. Ә без яңалыкны сынаган арада, агачтан тәрәзә рамы ясаучылар бармак белән генә санарлык калып бара икән ләбаса. Шуларның берсе – Арча районының Мәтәскә авылыннан Ринат Нәбиуллин. Ул – бүгенге көндә тәрәзә рамнарын заманча итеп, өч кат пыяла куеп ясаучы бик сирәк осталарның берсе.

– Мин үзем дә, яңалыкка кызыгып, иң беренче пластик тәрәзәләрне ясаучыларның берсе, – ди Ринат. – Стеклопакет, дибез. Өч кат пыяла үзара беркетелгән була, иң мөһиме шул бит инде. Ул хәзер әзер килеш сатыла. Башлангыч чорда без аны да кулдан үзебез ясый идек. Бик авыр эш, пыялага киселүчеләр дә булды. Бераздан пластик тәрәзәләрнең кире нәтиҗәсен дә күрә башладык. Тәрәзәләр тирли, астма белән авыручылар зарлана, балаларга гел тискәре тәэсир итә. Барыбызга да җайлыдан-җайлы гына кирәк. Имеш, куйдың да 25 елга тәрәзәләр турында оныттың. Дөрес итеп ясап, буяп куйсаң, аның агачлары да 25 ел тора. Авыллардагы, хәер, шәһәрдәге иске йортларның рамнары да әллә кайчан куелган. Утынга кисим дисәң, пычкы үтми. Бүгенге көндә нинди генә буяулар юк. Ел саен буйыйсы да түгел.

Оста буларак үзенчә нәтиҗә ясаганнан соң, Ринат Нәбиуллин агач рамнар ясарга тотына. Ул аның өчен башта хобби кебегрәк була. Акрынлап яңа җиһазлар ала һәм заманча итеп өч кат пыяла куеп, тәрәзәләр ясый башлый.

– Агач эше бик күп сабырлык һәм тырышлык сорый, бигрәк тә тәрәзәләр. Безнең шартларда таләп бигрәк тә зур. Әле салкын, әле эссе. Табигатьнең үзгәрешләренә тәрәзәләр дә каршы тора алырга тиеш. Җил тә үтмәсен, парланмасын да, матур да булсын.

Ринат ишекләр дә ясый.

– Хәзер тимер ишекләр куялар, шәһәрдә берни түгел, кирпечтән салынган авыл йортларында, коттеджларда алар да тышкы яктан бәзләнәләр. Йорт ничектер «суларга» тиеш. Агачтан ясалган тәрәзә һәм ишекләр менә шуның өчен кирәк тә инде. Сәламәтлегенең кадерен белгән кеше пластик тәрәзә куйдыртмый. Авырудан интегеп, пластикны кабат агачка алыштыручылар бик күп. Тәрәзә рамнарын ясау буенча тәҗрибә уртаклашырга Швециягә, Финляндиягә бардым. Анда бар да агач. Халык, акрынлап, агачны бәяли башлады, ләкин нәрсәнедер югалтып та өлгердек бугай, – ди оста.

Ринат Нәбиуллин ясаган ишекләрне, тәрәзә рамнарын күреп хәйран каласың. Заманча җиһазлар, материаллар белән аны менә шулай итеп тә ясап була икән. Яхшыны яманнан аерып, бәяләп өлгергәнче, агач осталарыбыз югалып, әлеге һөнәр онытылып кына бетмәсен иде.

**Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА,**
Арча, Мәтәскә.

АШ БУЛСЫН

# Рәфилә Шәмсетдиновадан «фирменный» ит пәрәмәче

**Камыр өчен:** *1 йомырка, 1/4 стакан шикәр комы, 1 ч.к. тоз, 1/4 чи чүпрә яки 1 а.к. коры чүпрә, 6 а.к. сыек май, 0,5 л җылымса кайнаган су*

Барлык ингредиентларны кушып, уртача тыгызлыктагы камыр басарга, артык йомшак һәм артык каты да булмасын. Камырны, өстен каплап, 1 сәгать җылымса урында тотарга.

**Эчлеге:** *500 г ит фаршы, 1 баш зур суган, 1,5 стакан дөге, 2 лавр яфрагы, 1 а.к. тоз, тәменчә кара борыч, 100 г сыер мае*

Суганны ваклап турарга, дөгене сүрән утта бүрттерәсе, сыер маен эретәсе, лавр яфрагын ваклыйсы. Барлык ингредиентларны бергә кушып, эчлеген ясарга. Камырны өлешләргә бүлеп, түгәрәкләр җәяргә, уртасына эчлекне куеп, пәрәмәчләр ясарга. Майлы табаларга тезеп, 200 градуслы мичтә 45 минут пешерергә. Пешеп чыгар алдыннан, пәрәмәчләрнең өстендәге уемына берәр ч.к. шулпа өстәп чыгасы. Шулпа урынына 2 а.к. сыер маен кайнар суда эретеп салырга да була.

ФАЙДАЛЫ

Ниһаять, җәй җитте кебек. Тиздән бакчада җиләк-җимешләр өлгерә башлар. Гадәттә, иң беренче булып без бакча җиләгеннән (виктория) авыз итәбез. Әлеге җиләк С витаминына бай. Аскорбин иммунитетны ныгытып кына калмый, салкын тиюдән дә саклый. Аңарда шулай ук А витамины бар, әлеге витамин исә тән тиресен картаймый. Җиләктәге бета-каротин үзләштерелсен өчен, организмга май кирәк, шуңа да белгечләр аны йогырт яки каймак белән ашарга куша. Виктория йөрәк өчен дә файдалы. Ул кандагы начар холестерин күләмен киметә. Җиләк хәтерне сакларга да булыша. Америка галимнәре шундый нәтиҗәгә килгән. Алар җиләктә канда җыелып килә һәм баш миенә тискәре йогынты ясый торган аксымга каршы көрәшә торган матдә тапкан.

БЕЛӘСЕЗМЕ?

Хөрмә җимеше йөрәк, бавыр, бөерне ныгыта.
Канны тукландыра, гипертония һәм анемиядән файдалы.
Иммунитетны ныгыта.
Ютәлне тынычландыра.
Яман шешкә каршы көрәшә.
Баш миен яхшы эшләтә.
Баш миендәге кан юлларын да чистарта.

ЯШЕЛ ДАРУХАНӘ

Кычыткан чүп үләне генә түгел, белеп кулланганда дару да. Кычыткан яфрагы K, $B_2$, $B_3$ витаминнарына бай. Аның составында шулай ук дуплау матдәләре, органик кислоталар, крахмал, шикәр, хлорофилл бар.

Кычытканның файдалы үзлекләренә килгәндә, аңарда К витамины һәм дуплау матдәләре күп булганлыктан, аны кан китүне туктаткыч буларак файдаланалар. Аналыктан һәм борыннан кан киткәндә, даруханәләрдә сатыла торган сыек экстрактын кулланалар. Төнәтмә дә әзерләргә була. Моның өчен 1 стакан кайнар суга 15 гр вакланган яфрак салып, 10 минут төнәтәләр һәм суытып, көнгә 3-4 тапкыр 1әр аш кашыгы эчәләр.

Ревматизм вакытында кычытканның согы файдалы, аны көненә өч тапкыр бал белән яртышар стакан эчәләр.

Кандагы шикәр күләмен киметү өчен, яңа җыеп алынган ике аш кашыгы кычыткан яфрагын вак итеп турап, бер стакан кефирга салып, көненә 1-2 стакан эчәләр.

Үт куыгында таш булганда, яфракларны сыгып ясалган сокны көненә 2-3 тапкыр берәр чирек стакан (яки һәр ике сәгать саен берәр аш кашыгы) эчәләр.

**Әлеге рецептларны кулланыр алдыннан табиб белән киңәшләшегез.**

БАКЧАЧЫГА

МӘЛЕНӘ – ӘМӘЛЕ

# Үзенчәлекле итеп буяу серләре

ХУҖАБИКӘГӘ

*Җәй – ял иту генә түгел, ремонт ясау чоры да. Ремонттан соң күпләр тәрәзә пәрдәсен дә алыштыра. Тәрәзә пәрдәсе өчен күпме тукыма кирәген белү өчен иң элек аның нинди озынлыкта булуын уйларга кирәк. Аның өч төре бар: тәрәзә төбенә кадәр, аннан астарак һәм идәнгә чаклы. Беренче вариантны сайлаган очракта, ул тәрәзә төбеннән бер сантиметрга өстәрәк була. Икенче вариантта тәрәзә төбеннән 10-15 сантиметр түбән тора. Өченче вариантта идәнгә кадәр бер сантиметр ара булырга тиеш. Пәрдәнең озынлыгын билгеләү өчен линейка түгел, рулетка кулланыгыз. Ул дөресрәк үлчәргә булыша. Пәрдәнең киңлеген һәм озынлыгын үлчәгәнче, кәрнизне элегез. Киңлеген исәпләгәндә, бөкләп калдыру өчен, ике ягыннан берничә сантиметр өстәгез.*

*Пәрдәнең нинди формада булуына карап, тукыманың киңлеген билгелисез. Элмәк белән булса, кәрнизнең киңлеген 1 яки 2 смга тапкырлыйбыз.*

*Люверста яки стандарт лентада булса, кәрниз киңлеге размерын икеләтә аласыз.*

*Карандаш сырлы пәрдә булса, кәрнизнең киңлеген 2,5 смга тапкырлагыз.*

ИРЛӘР КОЛАГЫНА

# Мунча ташы: кайсысын сайларга?

**Мунча өчен нинди таш сайларга кирәк, аның кайсысы озак хезмәт итә, кайсысы яхшырак җылыта? Шул сорауларга җавап эзлибез.**

Таш нык булырга тиеш. Аны тикшереп карау өчен ташка чүкеч белән сугу да җитә. Начар таш тиз ярыла һәм вата. Тагын бер сынап карау алымы – аны каты итеп кыздырып, суга салу. Суда ватылмаса, таш нык дигән сүз.

Чуен таш, гади ташларга караганда, өч тапкыра тизрәк җылыта һәм җылыны да озак саклый, әмма ул тиз күгәрә һәм табигый таш кебек файда бирми.

Елга ташын күбесенчә тау елгалары ярларыннан җыялар. Аларны җыеп каты итеп кыздырырга һәм суга салырга кирәк. Бөтен булып ватылмыйча калганнарын мичкә куярга була. Ташларның размеры 10-12 см булырга тиеш. Ваграклары тиешле җылылыкны бирә алмаячак, ә артык зурлары тигез булмаган җылынудан тиз шартларга мөмкин.

Карелия порфириты җылылыкны бик озак саклый. Аны таштан салынган мунча һәм сауналар өчен дә кулланып була. Температураның кискен сикерешенә чыдамлы, ачык уттан курыкмый, су эләксә дә ярылмый.

Перидотитның җылылык сыешлыгы югары, зарарлы компонентлары да юк. Углекислый газ белән реакциягә кереп, һаваны чистарта. Аны мунчаның төбенә салу отышлы, өстенә башка төр ташларны куярга була.

Базальт – иң нык таш һәм бөтен төр мунчага да бара. Ярылмый да, ватылмый да, суны да үзенә сеңдерми. Еш ягыла торган мунча өчен әйбәт.

Кара диабез кыйммәт тә түгел, экологик яктан чиста да, әмма озак җылына, артык җылытсаң, үзенә бертөрле ис бирә башлый. Аның өстенә эфир майлары да сибәргә ярамый.

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА** әзерләде.

# Алар мәңгелеккә диңгез буена китте

## Германиянең Боден күле өстендә булган авиаһәлакәткә – 15 ел

**2002 елның 2 июль иртәсен кара болыт чорнап алгандай булды: Германия күгендә, диспетчер гаебе аркасында, Башкортстан авиалинияләренең «Ту-154» самолеты «DHL» компаниясенең «Боинг-757» йөк самолеты белән бәрелешә. Фаҗига шунысы белән бигрәк тә аянычлы: һәлак булганнарның күбесе – балалар иде. Башкортстан мәктәп укучыларының җәйге ялга Испаниягә барулары булган. 52 бала, укуда зур уңышлар казанган өчен, диңгезгә юллама белән бүләкләнә. Тик ялга баручы балалар ярты юлдан кире әйләнеп кайта. Ябык табутларда. Криминалистлар әти-әниләргә табутны ачмаска киңәш иткән...**
**Авиаһәлакәттә гаепледәр әле дә булса танылмаган. Бердәнбер шаһит Петер Нильсенны һәлакәттә үз гаиләсен югалткан Виталий Калоев үтерә. «Скайгайд» диспетчерлык компаниясе, гаебен тулысынча танымаса да, кайгы күргән һәр гаиләгә 150 000 евро түли. Билгеле, акча нинди генә күләмдә булмасын, бала кайгысын оныттырмый. Авиаһәлакәткә 15 ел үтте, әмма суд утырышлары бүгенге көнгә кадәр дәвам итә...**

**Зоя СОЛОШИНА**,
Башкортстан

Хамматовлар гаиләсе.

Әти-әнисе хәтерендә Артур шундый көләч булып саклана.

### «КИЧӘ БУЛГАН КЕБЕК...»

Үлгән артыннан үлеп булмый, ди халык. Бер гөнаһсыз сабыйларның вакытсыз өзелгән гомере истәлеген, аларның якты рухын саклап яшәр өчен исәннәр бар. Ә бит ул көнне бердәнбер балаларын югалткан әти-әниләр дә була. Хамматовлар гаиләсе – шундыйлардан. Алар әлеге фаҗигадә уллары Артурны югалтты. Соңрак гаиләдә тагын ике сабый туа: Тимурга бүген – 13, Искәндәргә – 9 яшь. Тырыш һәм бар яклап та талантлы булган абыйларын аларга һәрвакыт үрнәк итеп куялар.

– Артурның ялга киткәнен кичәгедәй хәтерлим, – ди әтисе Зөлфәт әфәнде. – Шаярыша-көлешә, поездга утырдылар. Уфадан Мәскәүгә барып виза алгач, Испаниягә очарга тиешләр иде. Шушы көнне нинди көләч йөзле балакәчләр булса, бүген дә шундый булып хәтердә саклана. Әйтерсең алар бик озакка диңгез буена китте...

Ул елның 2 июле сишәмбе иде. Һәрвакыттагыча, иртәнге чәй вакытында, эшкә киткәнче, Зөлфәт әфәнде телевизордан яңалыклар тапшыруын карый. «Германия күгендә Белоруссия авиалинияләре самолеты белән йөк ташучы «Боинг» бәрелешкән», дигән хәбәрне шунда ишетә. Эфирда ялгыш Белоруссия дип хәбәр итсәләр дә, самолет ватыклары күрсәткәч, бал корты төшкән эмблема буенча нәкъ аларның балалары очкан очкыч икәнен аңлап ала. Әти кешенең күңеле бу хәбәргә ышанмый, башка каналларга күчереп карый, анда да шул репортаж бара.

– Кич алар самолетка утырганда, җитәкчеләре Ирина Совчукка шалтыратып, хәлләрен белдем. «Артур янындамы?» – дигәч, ул шундук аңа трубканы бирде. «Хәлең ничек, улым?» – дигән сорауга ул: «Әти, барчылма, барысы да яхшы», – диде дә телефонны җитәкчеләренә кайтарды. Иринага телефонын сүндермәвен үтенеп, иртән янә шалтыратачагымны әйттем, әмма иртән аның телефоны җавап бирмәде. Шул минуттан бердәнбер улыбызны югалтканыбызны аңладым...

Ялга җибәрергәме-җибәрмәскәме дигән уй бөтенләй булмый, уллары бу ялга лаек бит! Самолетта берсеннән-берсе акыллы балалар: барысы да уку елын бары тик «бишле»гә генә тәмамлаган, республика олимпиадаларында призлы урыннар алганнар... Артур кечкенәдән чит илләр турында энциклопедияләр укыган, сәяхәт кылырга хыялланып яшәгән.

– Артур беренче сыйныфка баргач та, әтисе белән килешү төзеделәр: «бишле» ала икән, аңа 1 сум бирәбез, «дүртле»гә — 50 тиен, ә «өчле» ала икән, соңгы атнада җыелган барлык акчасы «яна». Беркайчан да «өчле» алып кайтмады, һәм эшләгән акчасын тәм-томга түгел, ә китапларга, компьютер курсларына тота иде. Шунысы гаҗәп: ул яшәргә ашыкты. Барлык нәрсәне дә алдан эшләү, алдан белү гадәте бар иде. Аллаһ тарафыннан аз вакыт бирелгәнен аңлаган, күрәсең. Нинди генә эшкә тотынмасын, кулыннан килә иде. Ул 11 ел, 11 көн яшәде һәм 11 көннән без аны җирләдек, — ди әнисе Ида ханым.

Хамматовлар бу көнне уллары Артурны гына түгел, 14 яшьлек туганнары Лиананы да югалта. Алар кечкенәдән бергә уйнап үсә, гомерләре дә бер көнне өзелә.

### «ОҖМАХКА КАДӘР ОЧТЫМ»

Күрәсең, бала күңеле нәрсә булачын сизгәндер, шул самолетта очкан Зоя Федотова китәр алдыннан көндәлегенә моңсу шигырь яза:

*«Я с месяца упала,*
*С его острого края.*
*Я летела долго*
*И долетела до рая».*

Инзилә исемле кызчык рәссам булган. Сәер, гадәти булмаган йортлар төшерә башлагач, әнисе, гаҗәпләнеп: «Нәрсә бу?» – дип сорагач, кыз: «Әни, төшемдә шулай күрдем», – дигән. Авиаһәлакәт нәтиҗәсендә очкычлар янып төшкән шәһәр Баден-Вюртембергта нәкъ шундый гадәти булмаган архитектуралы йортлар барлыгы әти-әнине дә гаҗәпкә сала.

Зилаирда яшәүче Вәлиевләр гаиләсе дә бу көнне бердәнбер улларын югалта. Венерның фотоаппараты сакланган. Ул – самолетта фотога төшкән бердәнбер бала.

– Бүген аңа 30 яшь булып, бәхетебезнең иге-чиге булмас иде. Хәтерлим: поездның тәрәзәсен ачты да: «Әти, мин сине сагыначакмын», – диде. Миңа әйткән соңгы сүзләре шул булды. Юк, вакыт дәваламый. Венер әле дә безнең күз алдында 15 яшьлек малай булып тора. Һәлакәттән соң бирелгән акчаны озак вакыт нәрсә эшләтергә белмәдек. Киенергәме, йорт алыргамы, әллә бөтенләй кайгыдан эчеп үлергәме? Хатыным белән утырып сөйләштек тә мәчет салырга булдык. Мәчетнең ишекләре ачык, Венер исемен йөртә, – ди әтисе Юнир Вәлиев.

### СӘЙЛӘНДӘЙ ӨЗЕЛДЕ ГОМЕР

Кайгыдан соң һәр гаиләнең язмышы башкача борылыш ала. Борчылудан картайган хатыннарын ташлап, яшь кызлар янына киткән әтиләр дә бар, өйдәге бала шау-шуын кайтару өчен, балалар йортыннан берничә бала алган гаиләләр дә, Зөлфәт белән Ида кебек, гаилә учагын дәвам итеп, яңадан бала тапканнар да бар...

Дима Багин менә тома ятим калган... Авиаһәлакәттә ул стюардесса булып эшләүче әнисен югалта. Ярты елдан соң бердәнбер терәге булган дәү әнисе дә үлә. Очын-очка ялгап яшәгән туганнарының Диманы тәрбияләргә мөмкинлекләре булмый. Малайны авиаһәлакәттән соң әнисенең мәетен самолеттан чыгарган немец полициясе хезмәткәре үз гаиләсенә ала. Мартиннарның үзләренең дә ике малайлары була. Иң кызыгы – үзләре немец булса да, исемнәре рус: Алеша һәм Иван. «Хатыйн Достоевскийның «Братья Карамазовы» әсәрен укып, геройларына гашыйк булганнан соң, улларыбызга әлеге исемнәрне бирдек», – дигән иде бер әңгәмәдә полиция хезмәткәре. Әсәрдәге өченче персонажны хәтерлисезме? Тормыш әдәби сюжетны кабатлый һәм бер йортта өч егетне туганлаштыра: аларның икесе – немец, ә берсе – рус.

Мартиннар ярдәме белән, Дима Европаның алдынгы мәктәп-колледжларында белем ала һәм үз максатына ирешә. Бүген ул – дипломлы авиатехник, пилот лицензиясе дә бар. Германиядә самолетлар ремонтлый торган компаниядә эшли. Узган елны Башкортстан кызына өйләнеп, аны үзе белән Европага алып киткән.

Хәсрәт күргән гаиләләр ел да 2 июль көнне һәлакәт урынына бара. Германия халкы аларны җылы кабул итә, 15 ел эчендә дуслашып-туганлашып беткәннәр, немецлар да Башкортстанга кунакка килеп йөри. Һәлакәт урынында һәр ата-ана каен, миләш агачы утырткан, бүген ул агачлар шаулап үсеп утыра. Анда бик тирән эчтәлекле һәйкәл дә куелган. Ул Виталий Калоевның кызының өзелгән энҗе муенсасына таянып эшләнелә. Яланда монумент булып ясалган зур 71 сәйлән таралып ята – алар өзелгән кеше гомерен сурәтли.

Фаҗига булган җирдә Боден күле һәм зәгыйфь балалар өчен интернат урнашкан. Һәлакәткә кадәр бер сабый, тәрбиячесе янына көн дә килеп: «Апа, безгә олы самолет килеп төшәчәк», – дип кабатлаган. Зәгыйфь бала ни генә сөйләми инде?! Әлбәттә, тәрбияче бу сүзләрне колагына да элмәгән. Самолетлар бәрелешкән төнне әлеге бала, җитәкчесе янына килеп: «Апа, әйттем бит, төште теге самолет», – дигән. Бу – бер мисал гына, аннан башка да бик күпләр фаҗига буласын алдан сизенгәндер...

Фаҗигадә һәлак булган сабыйлар Уфаның Көньяк зиратында җирләнгән. Каберләргә карасаң, алар самолет бортын хәтерләтә: ике рәт, икешәр урын, ә рәт башында һава корабының капитаны һәм пилотлары урын алган. Самолет Германиянең алма бакчасына төшкән, ә дин китапларында оҗмах алма бакчасы итеп сурәтләнә. Сабыйларның да урыны җәннәттәдер.

Республика балалар клиник хастаханәсенең баш табибы Рафаэль ШӘВӘЛИЕВ:

# «Баласының сәламәтлеген ата-ана үзе булдыра»

**Баланың сәламәтлеге, нигездә, ата-ана игътибарына бәйле, ди белгечләр. Республика балалар клиник хастаханәсенең баш табибы Рафаэль Шәвәлиев тә: «Бала абынып егылса, медицина ярдәменнән бигрәк, аңа ата-ананың җылы сүзе кирәк», – дигән фикердә. Бүгенге көндә еш очрый торган авырулар, аларны кисәтү һәм баланың сәламәтлегенә кагылышлы башка мөһим нәрсәләр турында табибның үзе белән сөйләштек.**

Эльвира МОЗАФФАР

### «БАЛАГА УЗУНЫ ТУЙ СӘЯХӘТЕ ВАКЫТЫНДА ПЛАНЛАШТЫРМАГЫЗ»

**– Рафаэль Фирнаялович, балаларда нинди авырулар ешрак очрый?**

– Хәзер үпкә ялкынсыну, ашказаны системасы авырулары, диабет, эндокринологиягә кагылышлы, гәүдә авырлыгы арту (симерү түгел) кебек авырулар арта бара. Бер нәрсәне ассызыклап әйтәсе килә: балачактагы авырулар киләчәктә үзен белдерә. Медицинада бу өлкәне өйрәнә торган фән дә бар. Кешенең бала, үсмер чорында кичергән авыруларын анализлап, ун елдан сәламәтлеге нинди буласын фаразларга мөмкин. Кайбер галимнәр, кешенең авыру тарихларын өйрәнеп, аның хәтта нинди чирдән үләсен дә әйтә ала.

**– Бу авыруларны кисәтү өчен нинди киңәшләр бирер идегез?**

– Ата-аналар үз балаларының сәламәтлеген үзләре булдыра. Баланың сәламәтлеге туганчы ук формалаша. Мин һәрчак кисәтәм: балага узуны туй сәяхәте вакытында планлаштырырга ярамый. Яшьләр арасында, өйләнешкәннән соң, туй сәяхәтенә чит илгә бару гадәте керде. Сәяхәт вакытында күп хатын-кыз балага уза, ә авырга узгач, очкычка утырырга киңәш ителми. Күктә радиация 10 тапкырга күбрәк. Яралгы өчен бу зыян салырга мөмкин.

Авыруларны кисәтүгә килгәндә, күп нәрсә ата-ананың тәрбиясенә бәйле. Кыз баланы кечкенәдән чисталыкка, пөхтәлеккә, җылы киенеп йөрергә, үзен сакларга өйрәтү мөһим. Сәламәт, тәртипле тормыш рәвеше алып бару кирәк. Авырлы чакта хатын-кызга үзенә аеруча игътибарлы булу сорала. Еш кына сабыйлар җитлекми туа. Бу бит балага ана карынында тиешле шартлар булмаудан килеп чыга. Анемия, гемоглобин төшү, кислород җитмәү, стресс, инфекция йоктыру, имгәнүләр нәтиҗәсендә сабый вакытыннан алда туа. Медицина алга китсә дә, барысын да эшләп бетерә алмый. Сабыйның карында чакта ук барлык әгъзалары да җитлегеп бетүе мөһим. Гаилә институты булдыру кирәк. Өлкәннәр: «Яшьләрнең үз акылы, кысылмыйбыз», – диләр, әмма алар үз киңәшләрен бирергә тиеш. Гореф-гадәтләр, традицияләр яшәгәндә генә дөрес тәрбия алырга мөмкин.

**– Үзегез дә дүрт бала атасы буларак, балага мөстәкыйльлек биргән саен, ул тормышка тизрәк яраклаша дигән фикер белән килешәсезме?**

– Ансыз булмый, билгеле, тик мөстәкыйльлек белән бергә ата-ана игътибары да булырга тиеш.

**– Балага ничә яшьтән мөстәкыйльлек бирергә ярый? Әйтик, кайчан өйдә үзен генә калдырырга, ничә яшьтә газ кабызырга рөхсәт итәргә була икән?**

– Бу – яшькә карамый, яшәү рәвешенә бәйле. Әгәр баланың сәламәтлегенә зыян китерердәй, имгәнү, җәрәхәтләнү очрагын китереп чыгарырдай факторлар юклыгын күрәсез, балага ышаныч бар икән, аңа мөстәкыйльлек бирергә була, ләкин шул ук вакытта контроль турында да онытырга ярамый. Хәзер баланы күзәтеп тору өчен җайланмалар, телефоннарда кушымталар бик күп.

### ТУП ТИСӘ ДӘ, БАРМАК СЫНА

**– Берсендә сез, Татарстанда балалар арасында имгәнү очраклары ел саен 8-10 процентка арта, дигән идегез. Сәбәбе нидә икән? Туп тисә дә, бармаклары сына бит. Әллә хәзер балаларның сөякләре нык түгелме?**

– Алай ук димәс идем. Балалар элек тә шул, хәзер дә, ә менә имгәнүгә китергән сәбәпләр, тән җәрәхәтләренең механизмы үзгәрде. Катлаулы имгәнүләр еш очрый, мотоцикл, велосипедлардан еш егылалар, нәтиҗәдә, дәвалану да озакка сузыла. Анналары, элек москит сеткалары юк иде, чебен-черки кермәсен өчен, тәрәзәгә марля куйганнар, форточкаларны ябып йөргәннәр. Селфи ясаулар булмаган, телевизор сирәк каралган. Балалар күзәтү астында булган. Бала абындымы, әнисе аны күреп ярдәм күрсәткән. Катырак егылса, хастаханәгә илткән. Хәзер башкача. Ата-ана күп вакытын телефонда уздыра, балага игътибар җитми.

**– Чит илдә дәвалану нәтиҗәлерәк, дигән ата-аналарга карашыгыз?**

– Мин һәр ата-ананы аңлыйм. Алар балалары өчен иң яхшы шартларны сайлый. Әгәр чит илгә дәваланырга китәргә телиләр икән, без һәрчак ярдәм итәбез, авыру турындагы белешмәләрне чит телгә тәрҗемә итеп бирәбез, телемедицина ярдәмендә, табиблар белән элемтәгә чыгабыз. Чит ил тәҗрибәсен уртаклашу үзебез өчен дә файдалы. Безнең клиникага да ел саен чит илдән табиблар килә. Алардан яңа технологияләр өйрәнәбез, бездәге алымнары күрсәтәбез. Тик шунысын да игътибарга алырга кирәк: вакыт һәрчак кысан. Читтә табиб эзләп вакыт үткәргәнче, без «алтын» сәгатьне бала файдасына кулланырга тырышабыз. Педиатрия өлкәсендә даими күзәтеп тору да кирәк бит. Олы кеше еллар буе бер кием белән йөри ала, ә балага, үскән саен, кечерәйгәне урынына яңасын алырга туры килә. Операция белән дә шулай ук: гел күзәтеп тору мөһим. Тик чит илгә даими барып тору күпләр өчен мөмкин түгел, күзәтү өзелә.

### «ИГЪТИБАР ҖИТМӘГӘН БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘРГӘ ӨЙРӘНДЕК»

**– Психологлар: «Ярату, наз, игътибар җитмәгән, имин булмаган гаиләдә тәрбияләнгән балалар агрессив булып үсә», – диләр. Бу балалар сәламәтлек ягыннан да аерыламы?**

– Республикада 796 мең бала исәпләнә. Шуларның 23 меңе имин булмаган гаиләдә яши. Бу – Татарстандагы барлык балаларның 5 проценты дигән сүз. Ни өчен балаларны аерабыз? Минем фәнни җитәкчем профессор Валерий Альбицкий: «Балалар белән эшләгәндә, һәрчак истә тот: алар арасында тормышка үпкәле, кимсетелгәннәре дә бар. Аларга игътибар, наз җитми», – дия иде. Әгәр табиб баланың нинди мохиттә яшәгәнен ачыклый алмаса, ул аңа тиешенчә дәва бирә алмый. Имин булмаган гаиләдә яшәүче балалар арасында йөрәк-кан тамырлары, ашказаны, сөяк-мускул авырулары еш очрый. Имин гаиләдә яшәүче балаларда авыру ихтималы 48-50 процент белән исәпләнсә, тәртипсез тормыш рәвеше алып барганнарда 75-78 процент санала. Шуңа да бу балаларга аеруча игътибар кирәк. Татарстанда без мондый балалар белән эшләргә өйрәндек. Балалар сәламәтлеге үзәге, Россия фәнни-тикшерү медицина университеты, Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә, Республика балалар клиник хастаханәсе социаль яктан авыр хәлдә калган балаларга ничек ярдәм итәргә кирәклеге турында кулланма эшләп чыгарды. Без бу өлкәдә беренче булдык. Күптән түгел Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы – Татарстан үрнәгендә бу эш һәр төбәктә оештырылырга тиеш, дип күрсәтмә бирде.

**– Ә нинди нәтиҗәләр бар?**

– Сәламәтлек саклау системасы башка органнар белән дә тыгыз элемтәдә эшли. Учеттан төшкән балаларны контрольдә тотабыз. Балалар табибы бер пациентны, гадәттә, 15 минут кабул итә, ә имин булмаган гаиләдә тәрбияләнүчегә күпкә озаграк вакыт таләп ителә. Шуңа да мондый балалар өчен аерым үзәк эшли, аларны махсус табиблар тикшерә. Өйләренә чыгып, тормыш шартларын да карыйлар. «Азино» балалар сырхауханәсендә социаль яклау бүлеге хезмәткәрләре дә эшли.

**– Республика балалар клиник хастаханәсенең 40 еллыгын искә алмасак, әңгәмәбез тулы булмас кебек. Сез 2010 елдан бирле әлеге хастаханәне җитәклисез. Моннан 40 ел элек республикада беренче булып ачылган балалар хастаханәсе күп күрсәткечләр буенча бүген дә беренче булып кала бирә. Уңышларыгызны тагын бер барлыйк әле.**

– 40 ел – юбилей түгел. Төп максатыбыз – шушы форсаттан файдаланып, ветераннарыбызга, хастаханәнең нигез ташын салуда катнашып, бүген дә башлаган юлларын дәвам итүче беренче җитәкчебез Евгений Карпухинга, табиблар: Дамира Галеева, Анатолий Фоминых, Наталья Криницкая һәм башкаларга рәхмәт сүзләрен җиткерү. Исән чакта кешенең кадерен белеп, хөрмәт күрсәтеп калырга кирәк. Без заманча алымнарны кулланып һәм традицияләрне саклап эшләргә тырышабыз. Һәр бүлектә төрле буын табибы эшли. Бу аңлашыла да: Идел буе федераль округында тәүлек буе эшли торган, иң катлаулы авыруларны да кабул иткән мондый балалар хастаханәсе башка юк. Димәк, безнең табибларга да каядыр китәргә, өйрәнергә урын юк дигән сүз. Шуңа да остазлар мәктәбен үз хастаханәбездә булдырдык. Яшьләрнең ветеран табиблардан киңәш сорап, тәҗрибә уртаклашып эшләве мөһим. Безнең хезмәтне бәяләүләре дә сөендерә. Күптән түгел Росздравнадзор тарафыннан «Медицина хезмәтенең куркынычсызлыгы һәм сыйфаты» турындагы беренче номерлы сертификат тапшырылды. Иң мөһиме – балаларның сәламәтлеге. Без һәр баланы кайгыртабыз.

**– Әңгәмәгез өчен рәхмәт, эшегездә яңа уңышлар телибез!**

«Алтын битлек» премиясе иясе Илһам ВӘЛИЕВ:

КУНАК БҮЛМӘСЕ

# «Чын җырчылар хәзер модада түгел»

**Аның исеме – Илһам Шакировтан. Әтисе, яраткан җырчысы хөрмәтенә, улына Илһам исемен бирә. Үзе исә балаларына, Зөһрә Сәхабиева һәм Хәйдәр Бигичев хөрмәтенә, шул исемнәрне сайлый. Вәлиевләр гаиләсендә бар да югары сәнгатькә мөкиббән. Өйләрендә һәрвакыт классик музыка яңгырый. Бу – һәр гаилә әгъзасының күңел теләге.**

vk.com

**Тулы исеме:** Илһам Фәһим улы Вәлиев.

**Туган көне:** 1975 елның 19 июле.

**Туган җире:** Башкортстанның Чакмагыш районы, Иманлекул авылы.

**Гаилә хәле:** өйләнгән. **Хатыны –** Ләйсән, **балалары:** Зөһрә, Хәйдәр, Искәндәр.

**Яраткан ризыгы:** зур бәлеш, шулпа.

**– Илһам, әңгәмәне: «Мин опера җырчысы булам!» – дигән карарга китергән хатирәләрне барлаудан башлыйк әле.**

– Мин – гади авыл баласы. Әтием колхоз рәисе булгач, йортыбыздан кунаклар өзелмәде. Ә ул заманда колхозлар көчле, нинди генә бәйрәм булмасын, филармония артистларын чакыртып, концерт уздыралар иде. Ул артистлар безнең йортка аена икешәр-өчешәр тапкыр килде. Алар белән аралашып үстем, зур сәхнәгә тартылу алар аша уянды.

Үзлектән гармунда уйнарга өйрәндем, авылда, районда узган барлык үзешчән концертларда катнаштым. Үз телэгем белән, сәнгать училищесына укырга кердем. Ул вакытта үземне филармония җырчысы итеп күз алдына китерә идем. Опера юнәлешен сайлау уемда бөтенләй булмады, чөнки авыл баласы өчен классик әсәрләр ят, аның белән тәрбияләнмәдек. Баян, гармун моңнары, күбрәк халыкчан җырларны тыңлап үстем.

Укый-укый, классикага да ияләнеп киттем. Укытучылар да мактап, канатландырып җибәрде. Шул рәвешле үз-үземә ышаныч артты. Дүрт ел училищеда уку яхшы нәтиҗәләр бирде. Дәүләт имтиханын ВУЗ репертуары белән тапшырдым дип әйтергә дә була. Авыр арияләр башкарсам да, күңел барыбер үзебезнең халык, эстрада җырларын сорый иде.

Иң кызыгы сәнгать академиясенә укырга кергәч башланды. Анда программа җитди, хәер, югары белем шундый булырга тиеш инде. Мин III курста укып йөргәндә, Уфа опера һәм балет театрында Заһир Исмәгыйловның «Каһым Түрә» операсын әзерлиләр иде. Шунда башкорт халык җыры «Эскадрон»ны җырларга тәкъдим иттеләр. Бер генә куплетын. Ул роль сәхнәдә, булса, шул 3 минут булгандыр инде. Укытучым: «Театрга кереп, режиссерга шул җырны җырлап күрсәт әле», – диде. «Эскадрон»ны аңа кадәр Илһам абый, Абдулла Солтановлар башкаруында тыңлап, яхшы белә идем. Җырлап күрсәттем. «Шәп, иртәгә үк репетициягә киләсең», – диде режиссер Иркен Габитов. Ул мине опера сәхнәсенә чыгарды да.

Шул мизгелдән иҗатым, уйларым һәм хыялларым бөтенләй башка борылыш алды. Театр дөньясы, андагы тормыш… Ул бөтенләй башкача бит! Хәтта һәр театрның үзенә җәлеп итә торган исе дә бар.

«Әле бит мин студент кына. Эшләп карыйм, барып чыкмаса, ташлармын», – дип, үземдә артык ышаныч тоймыйча, бу эштә үземне сынап карарга булдым.

Әмма бу юлны сайлап ялгышмадым. Беренчедән, шәп педагогларда укыдым. Фәрзәнә Сәгыйтова мине вокал серләренә төшендерде. Опера буенча Марат Хисмәтуллин үзенең киңәшләрен кызганмады. Ул – легендар Мәгъфур Хисмәтуллинның улы, зур талант һәм көчле режиссер. Ул мине тәрбияләде: һәрбер жест, сәхнәдә үзеңне тоту. Чыгып җырлау гына түгел бит. Геройлар арасында мөнәсәбәт, аны тоемлау… «Беркайчан да уйнама, халык аңламаячак. Ә шул персонаж бул. «Шул герой булсам, нишләр идем?» – дигән сорауны алдыңа куй да аның тормышы белән яшә», – диде ул миңа. Уңыш сере шунда да. Ул бит кино караганда да сизелә: чын геройлар булса, алар белән бергә кайгырып, хәтта күзләр дә яшьләнә.

**– Әлбәттә, опера – зур талант сорый торган югары сәнгать, тик эстрада кеэмлерәк кебек бит?**

– Минем өчен бик авыр сорау бу. Хәзер сәхнәгә табын җырчылары, тамадалар менде шул. Табын арты форматы булса, керемлерәктер эстрада. Чын җырчылар хәзер модада түгел. Бу – заман шаукымы, бәлки ул үтеп тә китәр. Тик бер әйбер – аларның үзебезнең туган телдә җырлаулары гына шатландыра.

Бүгенге эстрада юлы минем өчен авыр булыр иде. Илһам абый, Хәйдәр абыйларны тыңлап үскәч, бүген халык тыңлаган эчтәлексез җырларны башкара алмыйм. Элекке әсәрләрне хәзер тыңламыйлар бит.

Солянка концертларында чыгыш ясый алмыйм. Бервакыт, яраткан җырчымның чыгышын карар өчен, җыелма концертка бардым һәм залда утырып шаккаттым. Хәзер тыңлаучының культурасы юк. Тамаша залына сыра, аракы, кабымлык алып кереп утыралар. Сикереп басалар, кычкыралар, чиныйлар… Бу бит коточкыч! Мондый концертлар мәдәни чара була алмый. Мине бу хәл бик борчый. Күңелдә начар тәэсир калды. Урамда үтә торган рок-фестивальләрдә генә андый хәл була дип уйлый идем. Юк, үзебезнең концертларда да икән! Солянкалар – мәдәниятебезне үстерү өстендә эшли торган концерт форматы түгел. Анда иң мөһиме: зал тулсын, кемдер сәхнәдә җырлап торсын. Бу – акча эшләү ысулы гына.

Әлбәттә, акча бар кешене дә кызыксындыра. Хәзерге заманда ансыз бер нәрсә дә эшләп булмый.

Опера сәнгатендәге эш хакына килгәндә, сүз дә юк, шоуменнар күбрәк ала. Екатеринбургта эшләгәндә, эш хакым гаиләмә җитәрлек иде, башка театрлар да рәнҗетмәде. Уфада да начар түгел. Аллага шөкер! Чәйлек, ипилек, шул ипигә, икрасы булмаса да, май ягарлык бар. Артыгы кирәкми.

Эстрада дигәннән, былтыр Казанда тәүге тапкыр сольный концертым булды. Аны Рәшит Ваһапов фонды җитәкчесе Рифат Фәттахов оештырды. «Әйдә, концертыңны куябыз. Син киләсең һәм җырлыйсың. Калган бар эшне дә үзем эшлим», – диде. Шулай булды да. Бөтен оештыру мәшәкатьләрен ул үз өстенә алды. Мин сәхнәгә чыгып җырладым да килешенгән гонорарны алып кайтып киттем. Менә шулай эшләргә була. Җитди продюсерлык үзәкләре тәкъдиме булса, кире какмыйм. Әмма җырчының үзенең концерт оештырып йөрүе – фантастикага тиң күренеш.

**– Сезнең хакта: «Татар теноры Казан опера театрында җырларга тиеш!» – диләр…**

– Казан опера театры минем өчен зур табышмак. Казанга килсәм, бөтенесе: «Сез нишләп бездә эшләмисез?» – дип аптырыйлар. Минем моңа җавабым юк. Үзем, ишек шакып: «Мине җырлатыгыз әле», – дип йөри алмыйм.

Казан – татарның мәккәсе, әлбәттә, ул – минем хыялда. Ходай язган булса, эшләрмен. Офыкта зур Мария театрын да күрәм… Әлегә эшсез утырмыйм: Уфа, Екатеринбург театрларында рольләрем бихисап, Алма-Атага да йөрим.

**– Гаиләгез иҗатыгызга ничек ярдәм итә?**

– Хатыным – иҗатымның фанаты. Ул фанатлар белән безнең өй тулган инде, барысы да музыкант! Бәхәсләшергә тотынсалар, ишетсәгез!.. Олы кызыбыз Зөһрә сәнгать училищесын тәмамлады, хәзер академиядә белем ала. Хәйдәр шулай ук сәнгать училищесында укый. Нигә еллар бергә яшәгәч, музыка белеме булмаса да, хатын да теләсә кайсы музыкаль критик белән аяк терәп сүз көрәштерә ала. Безнең өйдә – аерым бер консерватория. Балалар һәр спектаклемә йөри, чыгышымны бәяли, үз фикерләрен әйтәләр. Социаль челтәрләрдәге рәсми төркемнәрне дә алар алып бара. Кечкенәсе нинди юлны сайлар – әлегә билгесез. Искәндәргә – җиде яшь. Абыйсы йөргән «Тамыр» студиясендә шөгыльләнә. Бик сыгылмалы тәнле, нинди җыр ишетсә дә, биеп китә. Ритмны дөрес тоя.

Хатыныма, түзгәнгә, рәхмәт инде. Минем көйгә килү җиңел түгел. Мин аның дүртенче баласы.

**– Гадәттә, артистлар балаларының сәхнә юлын сайлавын теләми.**

– Мин каршы да килмәдем, мәҗбүриләмәдем дә. Үземнең мисалга килгәндә, әти теләге белән, башта авыл хуҗалыгы институтына укырга кердем. Аннан соң, механик булам, ә эштән соң үзем өчен гармунда уйнап җырлармын. Булачак механиклар арасында ярты ел буталып йөргәннән соң, әтигә кайттым: «Болай булмый. Сәнгать училищесына барам», – дип әйттем. Ул аңлады. Шунда калган булсам: «Эх, мин дә шул сәхнәдә булыр идем», – дип, башка җырчылардан көнләшеп, тилмереп йөрер идем, мөгаен.

**– Нинди җырны башкарганда рәхәтләнеп ял итәсез?**

– Соңгыларыдан – «Биек тауга менеп бер җырладым» (Хәйдәр җыры). Без аны Хәйдәр абыйның юбилеена әзерләдек. Концертта аны симфоник оркестр белән башкардым. Көчле килеп чыкты. Җырның язылу тарихы кызык. Хәйдәр Бигичев үзе шагыйрә Гөлшат Зәйнашевага шалтыратып, күңел халәтен, кичерешләрен сөйләгән булган. Шагыйрә аны әсәрендә сурәтләп биргән дә. Тик, кызганычка, Хәйәр абый үзе бу җырны башкарып өлгермәгән.

**– Опера җырчысы ничек ял итә? Киләсе чыгышына ничек көч туплый?**

– Сезон вакытында спектакльләр арасында бер-ике көн җырламый тору кирәк. Тыныч мохит булса, рәхәтләнеп ял итәм. Күңел тынычлыгы да бик мөһим. Борчылу тавышта шундук чагылыш таба. Хатыным, бөтен көнкүреш мәшәкатьләрен яшереп, миңа бары тик үз эшем белән генә шөгыльләнергә мөмкинлек бирә. Мин хәтта коммуналь хезмәтләр өчен кайда, кайчан һәм нәчә сум түләнгәнен дә белмим.

Әңгәмәдәш –
**Зоя СОЛОШИНА.**

ИМАНЛЫ СҮЗ

# «Алтын яки көмеш савыт-саба куллану хәрам»

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.)нең бер хәдисендә, ашказанын өч өлешкә бүләргә, шуның бер өлешен – ризык белән, икенче өлешен эчемлек белән тутырырга, өченче өлешен һава өчен калдырырга кирәк, диелә. Рамазан аенда вәгазьләр сөйләгәндә әлеге хәдисне бик күп имамнар искә алды, аларның сүзен, рәсми медицина да шулай куша дип, табиблар да раслады. Пәйгамбәребезнең ашау әдәбе турында тагын нинди хәдисләре бар? Гомумән, ул нәрсәләр белән тукланган, нинди ризыклар яраткан, сәламәт туклану буенча сәхабәләренә нәрсәләр киңәш иткән? «Өмет» мәчете имам хатибы Равил хәзрәт Бикбаев белән без шул сорауларга җавап эзләдек.**

pinterest.com

– Ашказаны – бөтен авыруларның өедер, чама белеп ашау – дәваның башыдыр, дигән ул. Ураза аенда үзегез дә игътибар иткәнсездер: аз гына ашап куйгач та, ашказаны тулып китә. Ифтардан соң хәтта сәхәрне ашамаучылар да булды. Кешенең тәнен сәламәт тотар өчен аз гына ризык та җитә. Сәламәтлекнең нигезе – дөрес туклануда. Кыямәт көнендә дә кешедән соралачак беренче нигъмәт – сәламәтлеге булачак. Ашыйсыгыз килгәндә, ашыкмыйча, каударланмыйча, әз-әзләп, бүлеп-бүлеп ашагыз. Соңгы вакытта табиблар симез кешеләрнең саны артуын әйтә. Пәйгамбәребез дә, ахырзаманда минем өммәтемдә халык симерер, дигән. Ул ризыкны суытып ашарга кушкан, аның әйтүенчә, кайнар ризыкта бәрәкәт юк. Аны өреп суыту, иснәп карау дөрес түгел. Мөселман кешесе уң кул белән ашарга тиеш, чөнки сул кул белән шайтан ашый, чалкан яки корсагына яткан килеш ашаудан, шулай ук йөргәндә һәм басып ашаудан сакланырга кирәк. Ашаганнан соң йокларга яту әйбәт түгел. Ашап бетергәч, тешләрне чистартырга һәм кулларны юарга киңәш ителә. Аллаһ Илчесе ризыкны гаепләп сүз әйтмәгән. Эчемлекне ике-өч йотым белән эчкән, савытка суламаган, мөмкинлеге булганда, савыт авызыннан эчмәгән, эчемлеген утырып эчә торган булган. Ашаган ризыгыгыз хәләл булсын. Хәрам ризык Аллаһтан ерагайта, андый ризык ашаган кешенең догасы кабул булмый. Хәрамнән никадәр ераклашсак, Аның кушканнарын үтәсәк, Аллаһка шулкадәр якынаербыз.

**– Хәзрәт, кемдер мөселманнарга гөмбә ашарга ярамый, ди, икенчеләр, Пәйгамбәр гөмбә ашарга яраткан, диләр...**

– Мөселманнарга гөмбә ашарга ярый. Ә Пәйгамбәр исә, далада үсә торган трюфель гөмбәсендә шифа бар, дигән. Хәдистә әйтелгәнчә, гөмбәдәге сыекча күзләргә дәва булып тора. Пәйгамбәребезнең үзе гөмбә ашавы турындагы хәдисне белмим.

**– Пәйгамбәребез тагын нәрсәләр яраткан?**

– Ит яраткан, бал ашаган, сөт эчкән. Сәхабәләре аның кабакны яратып ашавын да күргәннәр. Хөрмәне исә каймак белән ашарга яраткан. Шулай ук виноград, карбыз, кавын ашаганы турында хәдисләрдә әйтелә. Пәйгамбәребез булган әйберне ашаган, булмаган әйберне таптырмаган, күп вакытта аның ризыгы хөрмә белән су булган, берәр ай буе өендә учакта ризык пешерелмәгән, аның тормышы бик гади булган.

**– Бер хәдистә, ризыкка чебен бер канаты белән төшсә, аның икенче канатын да батырып, шуннан соң алып ташларга кирәк, диелә. Бу нәрсәне аңлата?**

– Галимнәр әйтүенчә, чебеннең бер канатында – агу, икенчесендә шул агуны бетерә торган бактерияләр бар икән. Шуңа да аны ике канаты да ризыкка тиярлек итеп батыру дөрес, әмма бу чебен төшкән ризыкны ашау мәҗбүри дигән сүз түгел. Җирәнгән кеше ашамаса да ярый.

**– Ялгыш кына төшеп киткән ризыкны нишләтергә?**

– Пәйгамбәребез аны алган да чистартып-өреп ашаган, югыйсә шайтанга китә, дигән. Аллаһы Тәгалә исраф итүчеләрне сөйми, ашамаган ризыгыгызны хайваннарга яки кошларга бирегез.

**– Мөселманнарга алтын һәм көмеш савыт-саба куллану тыеламы?**

– Ашау-эчү өчен алтын яки көмеш савыт-саба куллану хәрам, катгый рәвештә тыелган.

**– Ашар алдыннан бисмилланы әйтергә онытсаң нишләргә?**

– Бисмилла әйтүне күпчелек галимнәр – сөннәт, кайбер галимнәр ваҗиб ди, шуңа күрә аны әйтергә онытмаска кирәк, ә оныткан очракта: «Бисмилләһи-фи-әвәлиһи-вә-ахыйриһи», – дип әйтегез. Тәрҗемәсе: «Бу ризыкны Аллаһы исеме белән ашый башладым һәм тәмамлыйм».

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.**

## Өйдән чыкканда укыла торган дога

***Бисмилләәһи тәвәккәлтү гәләллааһ. Ләә хәүлә үә ләә куввәтә иллләә билләәһил гәлиййиль гәзыййм.***

**Тәрҗемәсе:** Аллаһ исеме белән тәвәккәлләдем Аллаһка! Бөек, олуг булган Аллаһтан башка бернинди дә хәл һәм көч-куәт булмас.

СОРАУ-ҖАВАП

Укучыларыбыз сорауларына «Гаилә» мәчете имам хатибы **Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН** җавап бирә.

**– Исламда музыка тыңлау рөхсәт ителәме?**

– Музыка тыңлау күпчелек ислам галимнәре тарафыннан хупланмый. Ни өчен дигәндә, музыка бит төрле була. Күңелдә шәһвәт, агрессия уята, нәфесне арттыра яисә күңел төшенкелегенә китерә торганнарын тыңларга ярамый. Көе, сүзләре Аллаһка, Пәйгамбәребез (с.г.с.)гә, ата-анага, ватанга мәхәббәт хисләре уята, рухи яктан баета торган җырлардан зарар булмас, иншаллаһ. Пәйгамбәребез, дөңгер (бубен) кебек уен коралларында уйнап, күңел ачуны тыймаган, ләкин һәрнәрсәдә чаманы белү кирәк. Фарыз гамәлләрне үтәмичә, дөньяңны онытып, мөкиббән китеп музыка тыңлау юньлегә илтми.

**– Хаҗда кылган намаз ун мең намазга тора, диләр. Хаҗга барып, күп итеп намаз укысам, минем өстән казага калган намазлар төшәрме икән?**

– Ун мең дигәндә, монда намазның әҗере турында сүз бара. Фикъһ гыйлеме буенча карасак, казага калган намазларны без бергә-бер укып бетерергә тиеш. Күбрәк нәфел намазлары укырга тырышсак, саваплары языла, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә безгә рәхимле булыр дип өметләнәбез.

**– Заправкада, сез моны лотереяда оттыгыз, дип биялэйләр бирделәр. Бу хәләл булырмы икән?**

– Мин монда гөнаһ күрмим. Әгәр дә сез махсус лотерея сата торган җиргә барып, лотерея сатып алсагыз, бу дөрес булмас иде.

(«Мөселманнар»)

## Июль аена намаз вакытлары

| Көн | Көн исеме | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Зәвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Шим | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 2 | Якш | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 3 | Дүш | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:29 | 21:59 |
